Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 45 (1410) 18 ноябрь 2022 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga madani_zhomga



6 **Г. Камал театрының М.Галәү әсәрләре нигезендә куелган спектакле автор житкерергә теләгән фикерне ачтымы, әллә...**

12 **Башкортстанның Ярмәкәй районындагы Исламбакты авылы XVIII гасырда Татарстанның Актаныш районыннан күченгән гаиләләр белән үсеп китә.**

14 **Күренекле фотограф Рамил Гали һөнәренең бүгенгесе, үзе житәкләгән берлекнең эше, хыял-ниятләре турында сөйләде.**

Килер көнең бәрәкәтле булыр, Кад(е)рен белсәң асыл мирасның!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

● Татарстанның халык шагыйре Рәдиф Гаташ «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале һәм язучы, җәмәгать эшлеклесе Роза Туфитуллова Татарстан Президентының Рәхмәт хаты белән бүләкләнде.

● 2022 елның 15 ноябреннән 31 декабрьгә кадәр 18 яшькә кадәрге балалар Татарстан Мәдәният министрлыгы карамагындагы музейлар һәм музей-тыюлыкларга бушлай керә ала.

● Уфаның М.Солтанова исемендәге мәдрәсәсендә галим, мәгърифәтче Ризаэтдин Фәхретдинне искә алып, аның фәнни-дини хезмәтләрен өйрәнүгә багышланган фәнни-гамәли җыен уздырдылар.

● Лениногорскиның Яңа Шөгер авылында шушы авылда гомер итүче рәссам Мансур ага Закировның шәхси күргәзмәсе ачылды.

● Түбән Каманың Бакый Урманче бульварында җәяү йөрү зонасы, арт-объектлар һәм рәссамга һәйкәл барлыкка киләчәк.

● Нефтекама дәүләт филармониясендә «Түңгәвер» ансамбленә нигез салучы, талантлы хореограф һәм балетмейстер Ривхәт Саттаров истәлегенә мемориаль такта куелды.

● Халык мәдәнияте антологиясе кысаларында Россия халыкларының 100 матди булмаган мәдәни объекты исемлегендә «Каравон» бәйрәме, «Казан җөе» – күнне тоташтыру буенча татар традицион техникасы, Рус Никольское авылының традицион киемнәре тәкъдим ителгән.

● Ульяновск шәһәренең Татар мәдәнияте үзәгендә Федераль Сабантуй бәйрәменә багышланган «Мәңге яшь Сабантуй» фотокүргәзмәсе ачылды.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Марсель ГАЛИЕВ, Татарстанның халык язучысы:

«Телебезгә күләгә төшерү булды. Аның тамырында тектоник тетрәүләр бара икән, шул вакытта телгә ниндидер ябырылу, аның уңышсыз якларын күрсәтү кирәкми. Андый вакытта тел турында сөйләргә ярамый. «Боларның телләре әле эшләнеп бетмәгән, нишләп өйрәним мин», – дип әйтәчәкләр».

СЫНАМЫШЛАР

21 ноябрьдә агачларны бәс сарса, кышын кар күп була; кич томан төшсә – тиздән җепшетә ● 22 ноябрьдән чын кыш башлана; бу көнне болытлы һәм карлы булса, майда салкын һәм яңгырлы була; яңгыр яуса – бодай уңа ● 24 ноябрьдә коры һәм җилсез булса, кыш җылы килә, киресенчә икән, салкын була.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **7 сәгать 24 минутта** чыкты, һәм ул **15 сәгать 32 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **8 сәгать 08 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **23 минутка кыскарачак** һәм киләсе җомгада, ягъни **25 ноябрьдә 7 сәгать 45 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

18 ноябрь – җырчы, Россиянең, Татарстанны, һәм Каракалпакстанның халык артисты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Ренат Ислам улы Ибраһимовның тууына 75ел (1947-2022).

21 ноябрь – Бөтендөнья телевидение көне.

22 ноябрь – җырчы, профессор, Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Зөләйха Гатаулла кызы Хисмәтуллинаның тууына 100 ел (1922–1994);

– Халыкара музыка көне.

23 ноябрь – кино һәм театр актрисасы, Россиянең атказанган артисты Фәридә Шамил кызы Мөэминовага 65 яшь (1957).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Ноябрьнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көнне исегезгә төшерәбез: 18 ноябрь.**

* * *

Гадәттә, айның соңгы чирегеннән яңа айга кадәр **(16-24 ноябрь)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә юан эчәклекне чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **25 октябрьдән 31 декабрьгә кадәр** бөер һәм бәвел куыгы актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны ныгыту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген рабигүл ахир аеның 24 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Вахит ИМАМОВ

ТАТАР КЕМНЕ БАЕТА?

(Тарихчы галим Таһир КӘРИМОВның “Бүләр волосте” исемле кульязма китабы буенча)

Бүгенге Актаныш районы территориясен элек Гәрәй, Йәнәй, Кыргыз, Байлар, Бүләр, Елан волостьлары, аларның җир биләмәләре тәшкил иткән. Башкорт мөтәгалимнәре, бармактан суырып, үз милләтләре элек 40 ыруны тәшкил иткән һәм алар Чулман ярыннан башлап Себердәге Тубыл дәрьясына кадәр җәелгән очсыз-кырыйсыз җирләргә хуҗа булган, дип күзгә төтен җибәрә. Мондый ялган «галимнәр» фикеренә буйсынып иярсәң, безнең Актаныш районы, яисә тулысынча элекке Минзәлә өязе биләмәләре дә бу шомабашлар уйлап тапкан, әмма халык саны буенча башкортлардан әллә ничә тапкыр күбрәк булган Гәрәй кабиләсе һәм байлар, бүләр, кыргыз, йәнәй, юрми, сарайлы-мең, ирәкте, елан... шикелле «ыру» җирләреннән торган һәм шушы биләмәләрдә биш гасыр элек үк гомер иткән бабаларыбыз да башкорт милләтен формалаштыруда катнашкан, аның үзәген-төшен хасил иткән булып чыга. Кыскартып әйткәндә, Гәрәй кабиләсе вәкилләре булып бер мең ел буе күкрәк киереп йөргән һәм сигез гасыр буе Кырым ярымутравын үз кулында тоткан бөек татарлар да, Мәскәүнең туктаусыз талау походларыннан, аларның көчләп чукындыруыннан Кама аръягына качкан безнең бабайлар да 5-6 гасыр буе башкорт милләтен саклап калу, аның санын ишәйтү; икмәк пешерү, тукыма туку, тире эшкәртү остаханәләре ача-ача аларга бил бөккән үтә мескен милләт булып кала.

Гәрчә бөек татар халкы тарихның бер генә этабында да башкорт, казах, кыргыз, үзбәк, таҗик, төрекмән кебек күчмә халыкларның колы да, ялчысы да булмаган, без мең ярым ел элек үк үз дәүләтебезне корып, хәтта Алтын Урда кебек бөек каганат, Казан, Кырым, Әстерхан, Касыйм, Ногай Урдасы кебек данлы дәүләтләргә ия булып яшәгәнбез. Ә инде янә җир волостьларына әйләнеп кайтсак, Актаныш яки Минзәлә территориясендәге Гәрәй, Байлар, Бүләр, Кыргыз, Юрми, Ирәкте, Йәнәй, Елан, Сарайлы-Мең олысларының берсе генә дә ниндидер ыруларга, кода-кодачалыкка нигезләнеп төзелмәгән. Бездәге бер генә волость та фәкать байлар яки бүләр ыруы вәкилләреннән тормый, һәр олысны асыл татар, бөек татар вәкилләре хасил итә.

Ә нигә соң Байлар, Бүләр, Кыргыз, Елан олысымы? Чөнки волостьларның үзәген менә шушы исемдәге авыллар тәшкил иткән һәм шул авылларның исеме, күп очракта, олыс аты булып әйләнешкә кергән. Мисалга, бүген бер өлеше Тукай районында урнашкан Байлар волостеның үзәге хәзер бер-берсеннән 5-6 чакрым арадагы Иске һәм Яңа Байлар, Югары һәм Тау асты Байлары, совет чорында Таулар дип аталса да, заманында Тау Байлары исемнәре белән йөргән авыллардан бик зур олыс аты булып киткән. Йәнәй исемен элек Карабәк-Габдулла ханга ияреп, Кавказ итәгеннән күчеп килгән Коркыт бинең бер оныгы йөрткән дә, шушы бинең Кушык, Күккүз-Күзәш, Тәнеч исемле уллары үз авылларын нигезләп җәелгәч, әлеге зур биләмә Йәнәй атын алган. Кыргыз волостеның аты Сөн елгасы буендагы Кыргыз авылыннан таралган. Безнең бабайлар яшәгән Бүләр волостеның үзәген дә элек Бүләр-Байсар, Мари Бүләр, Татар Бүләре кебек авыллар хасил иткән. Күрәсездер, монда бернинди ырулык яки туган-тумачалыкның да катнашы юк. Волость – ул, гомумән, җир биләмәсе. Өяз яки өлкәләрне волостьларга бүлү идарәче катлам яки ханнарга үз биләмәләреннән һәм «кол»ларыннан ясак җыю, ил казнасына акча туплау өчен кирәк булган.

Актаныш төбәгендәге җирләр дә Казан ханлыгы чорында нәкъ менә шул мәркәзгә, шул үзәккә буйсынып яши. Иң беренче булып, бу җирлектәге Тыңламас авылы кешеләренә 1469-1478 елларда Казан таҗдары булып торган Ибраһим хан үзенең биләмә грамотасын бүләк итә. 1523 елда инде Кырымнан килеп Казан тәхетен эләктергән Сәхиб-Гәрәй хан да бүген Минзәлә белән Пучы арасына җәелгән Ык буйларын, соңыннан Мөшегә түбәсе дип аталачак биләмәне Шәех-Әхмәт атлы тарханга һәм аның туганнарына бүләк итә. Хәтта шушы ике мисал гына да Актаныш районы җирләрендә 1470-1520 елларда ук татар халкы хуҗа булып торуын һәм гөрләп гомер итүен исбатлый. Менә шулай, турыдан-туры Казан ханына буйсынып яшәүгә күрә, дәүләт үзе егылгач та, бу тараф «Казан юлы» дигән гомерлек ат ала. Һәм эш «коры» атта гына да түгел, әлеге төбәк, Казан егылгач, баскыннар изүеннән, көчләп чукындырудан качу өчен килгән дистә меңнәрләгән Казан татарларын үз эченә кабул итә.

Шәех-Әхмәт тархан исеменә Сәхиб-Гәрәй хан 1523 елда биргән ярлыкны 1577 елда Явыз Иван патша да расларга мәҗбүр була. Бүләр җир волосте турында беренче хәбәрләр тарихи документларда 1621-1622 елларда, ясак теркәү кенәгәләре уңаеннан телгә алына. Ни гаҗәп, Бүләр вотчинникларының һәркайсы патша чиновниклары алдында үзләренең җиргә хокукын «Казанда хан утырган чагында ук бүләп бирелгән биләмә», дип яклый. Ә бу, үз чиратында, Казан ханнарының да, татар җирбиләүчеләренең дә Кама аръягындагы биләмәләрне үзләренең туган җире, законлы җире дип раславын күрсәтә.

Казан өязеннән Кама аръягына күчеп утырган крестьяннарны әүвәл, алар иген игү белән шөгыльләнгән өчен, «чуаш» дип йөртәләр һәм документларга да шулай дип теркиләр, гәрчә без бүген яхшы белгән чуаш халкы белән элекке игенче татар «чуаш»ларының бернинди дә уртаклыгы юк. Иң үкенечсе шул: күбрәк җир биләмәсе эләктерү хакына «башкорт – җир хуҗасы» катламына язылганга күрә, аларның байтагы XVIII-XIX гасырларда «башкорт» милләте вәкиле булып исәпкә алына башлый. Ә 1850 еллар ахырында һәм 1860 елларда башында волостьтагы дистәләгән авылдан 15-20 шәр гаиләне «хәрби хезмәт» урынына – үзләре беркетелгән 25 нче кантон урнашкан Кызыл Яр, Сарт-Чишмә авылларына (бүгенге Нуриман һәм Кырмыскалы районнарында) күчереп утырткач, һич тә шик юк, аларның яртысы «ысын» башкорт булып җанисәпкә керә...

Бүләр авылы үзе 1640 еллардагы документларда еш телгә алына. Биләмә хуҗалары нинди сәбәптәндер тулы хокуклы вотчинник булып исәпләнә алмаган, шуңа күрә алар Гәрәй волосте вотчинниклары белән бер үк күләмдә ясак түләп килгән. «Гирейской волости деревни Бюляр Баубеку Кудайбахтин[у] с товарищи збору свою платят 53 куницы да в тот же оклад велено помогат[ь] гулящему башкирцу деревни То[р]юшевы Айтуганку Собакову по 5 куниц на год по челобитью тое ж волости деревни Бюляр башкирца Байсарка Козяшева», – дип язылга ул чор документларында (РГАДА. Ф. 1173, Оп. 1, Д. 468, Л. 14.). Байсар Күзәшев 1653 елда язган үтенечтә үзенең 80 яшьтә булуын һәм этиләренең үз биләмәләре өчен уллары (Байсар) туганнан бирле сусар һәм бал белән ясак түләп килүе турында искәртүен искә алсак, Бүләр авылы вәкилләре тәүге ясакны 1573 елда ук түли башлаган булып чыга.

Бүләр волосте турындагы яңа мәгълүматлар 1630 (искечә 7138) елгы ясак кенәгәләрендә дә теркәлгән. Ул Бүләр вотчиннигы Ходайбакты Сабанчинның бөтен волость өчен 53 сусар тиресе белән ясак түләп баруы хакында бәян итә. 1637 елда ясакны инде Баубәк Ходайбактин түли. 1639 елда волость өчен ясак түләүчеләр булып шул ук Баубәк һәм Бозав (?) Бикчаров (Бикчуров-?) белән Ходайбакты һәм Уразмәт Ямашевлар языла. 1650 елда 53 сусар тиресен янә Баубәк Ходайбактин белән Чурапан Нуралин илтеп түли. 1728 елда ясак түләүче Гомәр Туктаров өчен Баубәк – агасы, ә Ходайбакты Сабанчин белән Базяв Бикчаров бабай туры килә. 1739 елгы документ биләмәләрнең әлеге вотчинникларга Ходайбакты Сабанчин, Сабан Кунакусин, Ходайбакты Ямашев, Чурапан Нуразлин атлы ерак бабаларыннан мирас итеп калдырылган булуын ачып сала. Баубәк исеме тарихи документларда соңгы тапкыр 1697 елда, 53 сусар тиресе түләү уңаеннан телгә алына.

Әмма Бүләр волосте 1621 елда ук искә алына башласа да, ул хәтта 60 елдан соң да ахыргача оешып бетә алмаган сыман. Чөнки волость составында булган Мөшегә түбәсе (ул Ык елгасының сул ярында, Пучыга бик якын) 1680 елда Ирәкте волосте белән җир өчен туган бәхәстә Мөшегә волосте, дип телгә алына. Шушы ызгыш-тартыш аркасындамы, Мөшегә вотчинниклары Акеш Доскаев, Морзакай Юкәчиев һәм яңа керәшен Данил Иванов үзләренең биләмәсен Мөшегә волосте дип күрсәтә.

(Дәвамы 5 нче биттә).

МӘҖ Җидегән вакыйгалар хәбәрләр яңалыклар

Хакыйкатькә тугры юл

Планетабызда цивилизацияләр берлеге булдыру һәм алар арасында гармонияле (үзара ярашкан) яшәешкә ирешү, зурдан алганда, адәми затның әле яралтылышта ук тәгаенләнгән, әмма әлегәчә гамәлгә ашырылмаган илаһи бурычы, алай гына түгел, аның һәр чор өчен рухи үсеш һәм хакыйкатькә омтылу күрсәткече, ә ахыр чиктә инде кешелек цивилизациясенең Җирдәге яшәеш шарты да булып тора. Соңгысы исә бүгенге кискен чорда аның шактый ук катгый төстә куелуы белән дә раслана: йә ул шартны тәгәл итеп үтисең, йә инде җәһәннәмгә олагасың (ә аның юллары күптөрле: әйтик, иррациональ яшәү рәвеше нәтиҗәсендә Җирдә энергетика ресурсларының сәегуы яки табигатьтәге башка төрле һәлакәткә юлыгу сәбәпле, яисә планетабызда атом-төш сугышы кубуы нәтиҗәсендә һ.б.). Тик, шунысы да хак: төрле цивилизацияләр арасында гармонияле яшәештән башка аларның рухи берлеге була алмаган кебек, цивилизацияләрнең рухи берлегеннән башка гына алар арасында гармонияле яшәешкә дә ирешеп булмый, ягъни, илаһи яшәешнең ошбу ике шарты («кешелек цивилизациясенең симфониясе») үзара икеләкле бөтенлекне тәшкил итә. Димәк, аңа ирешү юлын да, геосәясәт өлкәсендә түгел, ә рухи кыйммәтләр югарылыгында, ягъни илаһият өлкәсендә эзләргә кирәк.

Фәлсәфи категория буларак, хакыйкать ул объектив чынбарлыкны аңлата. Әмма шәхеснең әзерлеге, аң дәрәҗәсе һәм дөньяга карашына бәйле рәвештә, бер үк нәрсә дә төрле кеше тарафыннан төрлечә кабул ителергә яки бәяләнергә мөмкин (моның ачык мисалын бүгенге хәлләргә карата мөнәсәбәттә дә күрәбез). Димәк, объектив чынбарлык кеше аңында дөрес чагылыш тапсын өчен, ул шәхеснең хакыйкатьне абсолют кыйммәтләр системасында күрә һәм бәяли белүе мәслихәт. Ә бу инде аннан илаһи категорияләрдә фикер йөртүне, димәк, илаһият кануннары буенча яшәвен дә таләп итә. Чөнки андый система кеше аңында фәкать шул чакта гына формалаша ала һәм ул бары тик шул чакта гына аны чолгап алган вакыйга вә күренешләрне адекват (тәңгәл) бәяли алачак. Шулай итеп, хәтта диалектик фикер йөртүләр аша да без илаһият кануннары буенча яшәүнең объектив зарурлык булуын аңлауга килдек. Ә бу инде цивилизацияләр берлеге булдыру һәм алар арасында гармонияле яшәешкә ирешүнең нигезен тәшкил итә.

Шуңа да игътибар итик, илаһият кануннары буенча яшәүгә кучүне күпләр ни өчендер дини йолаларны үтәүгә (мөселманнар өчен, әйтик, шәригать законнары буенча яшәүгә) кучү дип кенә аңлый. Әмма илаһият кануннарына яшәештәге (әле яралтылыштан ук килә торган) барлык закон вә закончалыклар да керә, ягъни алар физик дөнья һәм табигать законнары да, илаһи гыйлемлек серләрен дә колачлый. Беренчеләрен төрле фәннәр (физика, математика, химия, биология һ.б) өйрәнсә, Күк йогынтысындагылары инде Изге Китаплардагы серле мәгънәләр рәвешендә бирелә һәм эзотеризм (эниология фәне) аша ачыклана. Инде аңлашыла булыр, илаһият кануннары барлык диндәгеләр һәм хәтта атеистлар өчен дә уртак. Чөнки алар барлык инсаннарга да бердәй кагыла. Мәгәр, инсаниятнең һәр илдә кабул ителгән эчке законнарга буйсынып яшәргә мәҗбүр ителүе дә хак. Ә алар еш кына, сәяси яки икътисади ихтыяҗлардан чыгып, илаһият кануннарына (бигрәк тә әдәп-әхлак нормаларына һәм милли вә иҗтимагый яшәеш законнарына) каршы килеп тә кабул ителә. Нәкъ шул законнар милләтләр һәм цивилизацияләр арасындагы каршылык вә бәрелешләрне китереп чыгара да инде.

Бу җәһәттән, аерым игътибарны яңа гасырда Россиядә башланган үзенчәлекле сәяси процесслар һәм шул максатларда кабул ителгән законнар да җәлеп итә. Урталык җирләренең геосәяси бөтенлеген СССР таркалгач та саклап калу өчен, хакимияткә ул чакта яңа җитәкче китерелде һәм аңа карт-бланш (чикләнмәгән вәкаләтләр вә гамәл иреге) бирелде. Чечнядәге хәтәр хәлләр фонында илдә хакимият вертикале торгызылды һәм чикләнмәгән хакимлеккә корылган режим урнаштырылды, ә хакимиятнең демократик идарәне имитацияләү өчен калдырылган барлык тармаклары да (суд, парламент, башкарма хакимият, «дүртенче» хакимият) аңа буйсындырылды. Курчак парламент исә, сайлауны имитацияләү мөмкинлеге бирә торган законнар кабул итеп, сайлау системасын әлеге режимны хакимияттә саклау механизмына әверелдерде. Отыры инде илне «Зур Европа» проектына әзерли торган (милли күптөрлелекне бетерү, зур агломерацияләр төзү һ.б. күздә тоткан) законнар базасы да булдырылды. Хәлбуки, Көнбатыш һәм Россия әле бүген дә, капма-каршы яктан, әмма уртак максатларда (идарәдәге кавем өчен яңа дөньяви тәртип урнаштыру юнәлешендә) эш итә. Әйе, моңарчы юллар гел бормалы булды. Тик офыкта инде хакыйкатькә тугры юл да күренә.

Фоат УРАЗАЙ.

Татар шигърияте төрек телендә

Үз казаныңда гына кайнап әллә ни майтарып булмый. Бу инде күптән расланган хакыйкать. Ул теләсә кайсы өлкәдә, шул исәптән әдәбиятта да шулай. Татар әдәбияты җәүһәрләрен дә дөнья халкына таныту өчен аның башка халыклар телләренә тәрҗемә ителүе мәслихәт. Татар язучылар берлеге әгъзасы, тәрҗемәче Фатих Кутлу инде шактый еллар татар әдәбиятын төрекчәгә тәрҗемә итеп, язучыларыбызны, аларның әсәрләрен Төркиядә таныту белән шөгыльләнә.

Күптән түгел Фатих Кутлу тәрҗемәсендә Төркиянең абруйлы «Һәҗә» нәшриятында (Анкара) «Хәзерге заман татар хикәяләре антологиясе – XXI гасыр» җыентыгы дөнья күргән иде.

Татарстан язучылар берлегендә октябрь аенда татар язучылары әсәрләрен башка телләргә тәрҗемә итү мәсьәләсендә тагын бер яңалык булды. Төркиянең «Һәҗә» әдәби-нәфис журналының октябрь саны махсус татар шигъриятен танытуга багышлап чыгарылган. Анда тәрҗемәче Фатих Кутлуның кереш сүзе, аның Татарстан Язучылар берлеге рәисе, шагыйрь, язучы Ркаил Зәйдулла белән үткәргән әңгәмәсе, һәм 20 татар шагыйренең берәр шигыре урын алган. «Татар шигыренең үткәне, бүгенгесе, киләчәге» дигән интервьюда Р.Зәйдулла төрек укучыларына татар поэзиясенең тарихы, борынгы татар шагыйрьләре һәм аларның әсәрләре, туксанынчы еллардагы шигърият, яшь шагыйрьләр, татар поэзиясенең үзенчәлеге турында сөйли. Ул шулай ук Тукай заманыннан ук татар поэзиясенең төп темасы – дәүләтчелегебезне югалту газабы булуын, аны һәр шагыйрь үзенчә кичерүен искәртеп, татар шигъриятенең лирикадан гына тормавын ассызыклаган.

Шагыйрьләр Лилия Гыйбадуллина, Луиза Янсуар, Гөлүсә Батталова, Йолдыз Миңнуллина, Фәнил Гыйләҗев, Рифат Сәлах, Рузәл Мөхәммәтшин, Марат Кәбиров, Илсөяр Иксанова, Рифә Рахман, Ләис Зөлкарнәй, Ркаил Зәйдулла, Ләбиб Лерон, Сирин Якупова, Фирүзә Җамалетдинова, Газинур Морат һ.б. ның шигырьләре авторлар турында кыскача мәгълүмат белән бирелгән.

Шигырьләрне Фатих Кутлу тәрҗемә иткән. Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары, шагыйрә Илсөяр Иксанова искәрткәнчә, аның Казанда яшәве һәм татар телен өйрәнүе язучылар өчен зур бәхет. Фатих Кутлу – үз эшенә бик җаваплы карый торган кеше. Ул һәр автор белән элемтәгә кергән, акцентларны, сүзләрнең мәгънәләрен, образларны дөрес аңлау, шигырьнең музыкальлеген, интонациясен дөрес итеп тоту кебек четерекле мәсьәләләрне иҗатчылар белән бергәләп хәл иткән, шигырьләрнең һәркайсына шигырьнең төрекчә яңгырашын яздырып җибәргән.

Фатих әфәнде шигырьләрне татар шигъриятенең көчлелегенә, образларның матурлыгына хәйран калып тәрҗемә итүен әйтте. «Яшь буын аны шулай дәвам итсен, традицияләр югалмасын, татар шигърияте шул биеклеген саклап калсын иде», – диде ул.

Сөембикә КАШАПОВА.

Вәгазь сөйли беләсеңме?

Россия ислам институты дини уку йортлары студентлары арасында республикакүләм татарча вәгазь укучылар бәйгесенә гаризалар кабул итә. Әлеге бәйгедә республикабыздагы мәдрәсәләрдә һәм югары мөселман уку йортларының көндезге бүлегендә белем алучы студентлар катнаша ала. Бәйге Россия ислам институты башлангычы һәм ярдәме белән Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгы кысаларында уздырыла. Бәйге татар телен, мәдәниятен үстерү өчен өстәмә шартлар тудыру, яшь буында телне, рухи мирасны, ислам дине кануннарын өйрәнүгә кызыксыну уяту, тел һәм дин өлкәсендәге белем һәм күнекмәләрне камилләштерүне максат итеп куя.

Бәйгегә чыгышлар видео форматында кабул ителә. Вәгазьләр татар телендә, традицион формада сөйләнергә, яхшы сыйфатлы булырга, видеоязма 7-10 минуттан артмаска тиеш. Вәгазь темасы – ирекле. Видеоязмалар 11 декабрьгә кадәр кабул ителә; 17 декабрьгә кадәр жюри әгъзалары тарафыннан чыгышларга бәя бирелә.

Әлеге конкурста катнашу өчен, видеоязманы электрон почтага җибәрергә яки Казан шәһәре, Газовая урамы, 19 йорт, Россия ислам институты, татар теле һәм милли мәдәният кафедрасына (икенче кат, 222 бүлмә) тапшырырга мөмкин.

Эльмира СИРАҖИ.

Бәдигыйны әле өйрәнәсе бар

Г. Тукай музеенда «Тукай фатихасы белән» дигән әдәби-музыкаль кичә узды. Ул шагыйрь, тәнкыйтьче, галим, фольклорчы Хуҗа Бәдигыйнең 135 еллыгына багышланган иде.

«Хуҗа Бәдигый, беренче чиратта, Тукай лекциясен тыңлаган шәхес буларак искә төшә. Тукай белән һәр очрашуын хисләре белән дәлилләп сөйләгән кеше буларак күз алдына килә», – дип сәламләде музей мөдире Гүзәл Төхвәтова.

КФУның татар теле белеме кафедрасы доценты Энҗе Кадыйрова әйтүенчә, Хуҗа Бәдигый – хезмәтләре тулысынча ачылып җитмәгән галим. «Аның турында кечкенәдән үк белеп үстем, чөнки әти-әниләр безнең авылдан зур кеше чыкканын әйтә иде. Татар теле методикасы, татар синтаксисы, морфологиясе, предметларын укыганда да галимнең исемен укытучылар еш кабатлады», – диде ул.

«Татар телен гамәлгә кую башлангач, академик үзәк татар дәреслекләрен төзү комиссиясен оештыра. Анда Мөхетдин Корбангалиев, Галимҗан Шәрәф һәм Хуҗа Бәдигый була. Аның рус телле кешеләргә татар телен укыту юнәлешендәге дәреслекләре игътибарга лаек», – диде галимә.

Хуҗа Бәдигый татар теле һәм әдәбияты дәреслекләреннән тыш, табигать белеме һ.б. дәреслекләрен татарчага тәрҗемә итә. «Ул вакытта дәреслекләре шул кадәр актуаль була. Мәсәлән, Мөхетдин Корбангалиев белән бастырып чыгарган «Татар әлифбасы» биш тапкыр 39500 данә белән басыла. Аның татар әдәби теле тарихы, татар морфологиясе, синтаксисы, лексикологиясе юнәлешендә күпсанлы мәкаләләре бар», – ди Энҗе Кадыйрова.

Кичәне музейның өлкән фәнни хезмәткәре Лена Тябина алып барды. «Х.Бәдигыйның Роза исемле кызы булган. Ул Казан музыка училищесында, аннан соң Ленинград консерваториясендә укый. Хуҗа Бәдигыйның музыкаль таланты да булган дип әйтә алабыз», –диде ул.

Чарада Хуҗа Бәдигыйның Санкт-Петербург, Яшел Үзән, Казанда яшәүче туганнары, Г.Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында аның эшчәнлеген өйрәнгән галимнәр чыгыш ясады.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.

1 нче биттә – Сынлы сәнгать музеенда «Лихачёвлар. Тормыш – Ватанга хезмәт итү» конференциясе уңаеннан оештырылган күргәзмә экспонатлары.

Мәдәният йортларына кадрлар җитми

Казан дәүләт мәдәният институтында Татарстан Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты күчмә утырыш уздырды. Анда депутатлар республикада мәдәният йортлары, клублар эшчәнлеген тикшерде. Комитет утырышында Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов катнашты.

Мәдәният институты белән таныштыру экскурсиясе барышында депутатларга прототиплаштыру үзәге, костюм дизайнын проектлау лабораторияләре, нәфис агач эшкәртү, чүлмәк һәм керамик продукция ясау үзәкләре, тавыш яздыру студиясе, уку йортының интерактив музее тәкъдим ителде.

Комитет утырышында мәдәни-ял итү учреждениеләре челтәре эшчәнлеге турында Татарстан мәдәният министрлыгының беренче урынбасары Юлия Әдһәмова чыгыш ясады.

Республикада мәдәни-ял итү учреждениеләр челтәрен 1909 мәдәният йорты һәм клуб тәшкил итә. 117 мәдәни-ял итү учреждениесе музей эшчәнлеге белән шөгыльләнә. Хәзерге вакытта 466 бинага капиталь ремонт таләп ителә, 18 е авария хәлендә. 2012 елдан 2021 елга кадәр 331 күп функцияле үзәк (авыл мәдәният йортлары һәм клублар) төзелгән. Матди-техник базаны үстерүгә, тармак объектларын төзүгә һәм реконструкцияләүгә, мәдәният учреждениеләре җиһазларын комплекслы мәгълүматлаштыруга һәм модернизацияләүгә мәдәният үсешенә бүлеп бирелә торган акчаларның шактый өлеше җибәрелә.

Клуб инфраструктурасын үстерүдә кискен мәсьәләләр арасында профильле министрлык вәкиле тармакны кадрлар белән тәэмин итү проблемасын атады. Мәдәни-ял итү учреждениеләрендә 8808 кеше эшли. Шул ук вакытта белгечләр белән тәэмин ителеш нибары 76,6 % тәшкил итә. Клублар аккомпаниаторларга, халык һәм рухи инструментлар ансамбльләре җитәкчеләренә, режиссерларга, оештыручыларга, яктырту, тавыш техникасы инженерларына мохтаҗ. Проблема хезмәт хакы белән дә, кадрлар әзерләү системасы булмау, авыл халкының картаюы һәм башка объектив сәбәпләр белән дә бәйле. «2020 ел белән чагыштырганда, төбәктә клуб берләшмәләре 37 гә кимегән. 2021 елда берләшмәләр кыскартылуның төп сәбәбе – коронавирус инфекциясе таралу куркынычы белән барлыкка килгән чикләүләрнең саклануы һәм 65 яшьтән өлкән кешеләрнең изоляциядә булуы», – диде ул.

Казан Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе җитәкчесе Азат Абзалов, Арча район мәдәният сарае директоры Айрат Нуриҗанов һәм Аксубай районы мәдәният йорты директоры Ольга Копанева клублар учреждениеләре базасының торышы, аларның матди-техник тәэмин ителеше һәм методик ярдәм турында өстәмә мәгълүмат бирде. Алар гаммәви мәдәни чараларга ихтыяҗ булуы, сәхнә мәйданчыкларыннан һәм заллардан файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру чаралары, республикада яшәүче халыклар мәдәнияте үсеше өчен милли бәйрәмнәрнең әһәмияте турында сөйләде.

Казан дәүләт мәдәният институты ректоры, парламент комитеты каршындагы Эксперт советы рәисе Роза Әхмәдиева мәдәни-ял итү учреждениеләре челтәре торышын анализлады һәм тармак проблемаларын хәл итүгә юнәлтелгән тәкъдимнәр кертте. Клублар һәм мәдәният йортлары эшчәнлегендә кыенлыклар, аның сүзләренчә, барлыкка да элек, кадрларның эштә ныгып калмавы, матди-техник тәэмин ителешнең җитәрлек булмавы, эшчәнлекне оештыруның яңа формалары булмау белән бәйле. Хәлне яхшырту өчен институт ректоры кадрларны алдан укыту системасын оештыруга, учреждениеләрнең матди-техник базасын ныгыту структурасын камилләштерергә, мәдәният хезмәткәрләренә ярдәм күрсәтүне активлаштырырга тәкъдим итте.

Фикер алышуда катнашкан Марат Әхмәтов икътисади, спорт, реклама яки хисап характерындагы массакүләм чараларның санын түгел, ә сыйфатын күтәрү зарурлыгына игътибар итте.

Депутат Илшат Әминов клубтагы учреждениеләрнең эшчәнлеген бәяләү өчен мониторинг булу белән кызыксынды, ә депутат Александр Славутский Казан театр училищесын мәдәният институты составына кертергә тәкъдим итте.

Кандалый Мәскәүгә «килде»

Мәскәүнең Татар мәдәнияте үзәгендә XIX йөз татар шагыйре Габделҗәббар Кандалыйның рус телендәге шигырьләр җыентыгын тәкъдим иттеләр. Анда кергән текстларны шагыйрә һәм прозаик Лилия Агадуллина тәрҗемә иткән.

Җыентыкны шагыйрә үз хисабына бастырган. Китапта Кандалыйның хатын-кызга җавапсыз мәхәббәт темасына багышланган шигырьләре һәм поэмалары тупланган.

«Россиядә һәм Татарстанда Кандалыйның туууына 225 ел тулуга багышланган чаралар уза. Аның иҗатын популярлаштыруга күпмедер өлеш кертүемә шатмын. Мөмкин кадәр күбрәк кеше аның турында тагын да яхшырак белсен иде», – дип искәртте Л.Агадуллина.

Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, язучы, «Татарский мир» газетасының мөхәррире Ринат Мөхәммәдиев (китапны нәшер итүдә ул да катнашкан) әйтүенчә, татар әдәбияты турында сөйләгәндә, гәрчә ул аны үстерүгә гаять зур өлеш кертсә дә, кешеләр Кандалыйны бик сирәк искә ала. Аның лирик поэмалары татар әдәбиятының хәзерге яшәеш стадиясенә күчешен билгели.

«Габдулла Тукай, Муса Җәлилне генә түгел, Кандалыйны да пропагандаларга кирәк. Чөнки без үзебезнең күп гасырлык тарихыбыз турында сөйлибез һәм аны күрсәтергә кирәк», – дип белдерде Мөхәммәдиев.

Кичә кунаклары алдында Татар мәдәнияте үзәгенең иҗат коллективлары чыгыш ясады.

Чаллыда әдип һәм әдәбият бәйрәме

Чаллыда татар әдәбият көннәре узды. Аның кысаларында татар язучылары Мулланур Вахитов исемендәге 2 нче гимназия укучылары белән очрашты. Зиннур Мансуров, Марсель Галиев, Газинур Морат, Рүзәл Мөхәммәтшин, Рөстәм Галиуллин һ.б. язучылар Чаллы бүлегендәге каләмдәшләре белән берлектә шәһәрнең төрле мәктәпләрендә очрашуларда булды.

«Шигырь язарга өйрәнеп була. Әмма чын әсәр килеп чыксын өчен сәләт булырга тиеш.... Укырга, язарга өйрәнгәнче үк ритмлы такмаклар уйлап чыгара идем мин», – дип сөйләде Татарстан Язучылар берлеге рәисе, Татарстан Дәүләт Советы депутаты Ркаил Зәйдулла. – Укырга, язарга өйрәнгәч, башка иҗат әһелләренең шигырьләре белән таныштым. Такмакларымны кәгазьгә төшердем, газета-журналларга җибәрә башладым. Алтынчы сыйныфта укыганда «Яшь ленинчы» газетасында шигырем чыкты. Аннан соң мине шигырь язудан тукта алмадылар», – дип үзенең иҗаты белән таныштырды ул.

Чаллы Язучылар берлеге җитәкчесе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Факил Сафин укучыларга туган телне белү зарурлыгы турында искәртте. «Хәзерге чор шактый катлаулы. Балаларыбызны, оныкларыбызны татарча тәрбияләргә тырышабыз. Алар белән эш итәргә авыр. Ә аларның балалары белән нәрсә булыр? Уйларга куркыныч. Сезнең татарча матур сөйләгәнегезне күрү күңелдә өмет уята», – диде ул. Шагыйрә Айзирә Имамова иҗади яктан сәләтле кешенең тормышта югалып калмавын үзенең мисалында сөйләде.

Әдәби-мәдәни чаралар Аяз Гыйләҗев исемендәге Чаллы татар дәүләт драма театрында Ркаил Зәйдулланың «Син кара Шагыйрь кузенә...» дип исемләнгән иҗат кичәсе белән дәвам итте.

Татарстан Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов кичәдәге чыгышында Р.Зәйдуллага кыюлыгы, таланты, үзсүзлелеге, мөстәкыйль фикере өчен хөрмәте зур булуын әйтте. «Аллаһ Тәгалә аңа искиткеч күп талантны капчык-капчык биргән: үзе шагыйрь, язучы, публицист, тәрҗемәче, драматург, хәзер җәмәгать эшен алып бара. Шуңа күрә мондый мөмкинлеге, сәләте булган, халык тарафыннан кабул ителгән фикерле кешене безгә үзебезнең уртак максатыбызга файдаланырга кирәк», – диде ул.

«Мин үземне милли шагыйрь дип саныйм. Татар шагыйре, язучысы милләтенә төгәл сүз әйтергә дип яза. Без бергә булырга тиеш, телебезне, гореф-гадәтләрне сакларга һәм бербөтен булып яшәргә тиеш. Шундый «тиеш»ләр безне язарга мәҗбүр итә. Халык безнең сүзебезгә колак сала икән, бу күңелле хәл», – диде юбиляр Р.Зәйдулла.

Татарстанның халык язучысы М.Галиев үзенең «Кәефеңә кояш төшермә» дигән китабыннан бәйрәмдәр белән булган кызыклы хәлләрне сөйләде. Татарстанның халык шагыйре З.Мансуров Р.Зәйдуллага «татарча уйлап, татарча сөйләп, татарча язып, газиз милләтебезгә хезмәт итәргә язсын» дигән теләкләрен җиткерде.

«Казан утлары» журналы баш мөхәррире, язучы Р.Галиуллин аның һәр кеше белән уртак тел таба белүен, җиңел аралашып китүен билгеләп үтте. «Татар әдәбиятында шагыйрьләр Сибгат Хәким белән Хәсән Туфан, Илдар Юзеев белән Шәукәт Галиев дуслыгы дигән төшенчә яши. Бүгенге көндә Ркаил Зәйдулла белән Газинур Моратның 40 елдан артык дәвам иткән дуслыгы – безнең өчен үрнәк», – диде ул.

«Ркаилне мин 43 елдан артык ярыйсы ук яхшы белән икән. Безне күп тапкыр бутыйлар иде», – диде Татарстанның халык шагыйре Газинур Морат һәм юбилярга багышланган автобиографик шигырен яңгыратты.

Кичәдә Татарстанның халык артистлары Азат Тимершәех, Гөлдания Хәйруллина, Татарстанның атказанган артисты Равил Галиев, Туфан Миңнуллин исемендәге Түбән Кама дәүләт татар драма театры актерлары һ.б. чыгыш ясады.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.

● Татарстанның 12 уку йорты hh.ru төзегән Россиянең иң яхшы вузлары исемлегенә кертелгән. Андагы барлыгы 300 югары уку йорты арасында Казан федераль университеты – алтынчы урында. Рейтингка шулай ук КИТТУ-КХТИ, КИТТУ-КАИ, КДЭУ, «ТИСБИ» идарә университеты, КДАУ, В.Тимирясев исемендәге Казан инновацияләр университеты, КДМУ, КДМИ, КДАТУ, Әлмәт дәүләт нефть институты, КДВМА кертелгән. Исемлектә беренче урында – Мәскәүнең «Икътисад югары мәктәбе» Илкүләм тикшеренү университеты (НИУ ВШЭ).

● Халыкның матди байлыгы рейтингында Татарстан 13 нче урынга куелган. Бу хакта Росстат һәм РФ Банкы хәбәр итә. Узган ел нәтиҗәләре буенча республиканың әлеге исемлектәге баллы 51,38 кә, 2020 ел буенча 47,84 кә тиңгәл. Татарстанның рейтингтагы күршеләре – Камчатка крае (11 нче урын) һәм Свердловск өлкәсе (12 урын). Иң бай төбәкләр өчлегенә исә Ямал-Ненец округы, Чукотка автономияле округы, Магадан өлкәсе керә.

(Дәвамы. Башы 2 нче биттә).

ТАТАР КЕМНЕ БАЕТА?

Бик гаҗәп тоелса да, 1664 елда Сеңгерән авылы да (Сөн елгасының уң ярында, хәзер Илеш районында) волость үзәге итеп күрсәтелгән. Ул документларда Минзәлә төрмәсендә әманәт булып тотылучы Исенка Сармановны телгә алу уңаеннан күрсәтелә. Аны бертуган Галибай белән Сарыбай Иләкбирдеевларның берсе алыштырырга тиеш була. Хәтта XVIII гасыр азагындагы документларда да Сеңгерән түбәсе волость дип телгә алына, әмма бераздан ул Бүләр волосте составына кертелә. Ни гаҗәп: Сарыш-Кыпчак, Тәмьян, Табын, Кыпчак, Күрпеч-Табын авыллары да соңрак юкка чыккан волость үзәкләре булып санала.

Хәзер инде Бүләр волосте составына кергән авылларны барлыйк. Әнәк, Пучы, Чәчер, Илтимер авыллары 1683 елда игълан ителгән указ нигезендә килеп утыра. 1701 елда алар «биләмәләр хуҗасы» булуларын исбат итеп, «владенная грамота» алуга ирешә. Бу авыллардагы барча крестьяннар да 1764 елга кадәр – ясаклы татар, ә 1782 елгы җанисәптә типтәр булып язылa. Аннары инде, «владенная грамота»га ия булуларын искә төшереп, үзләренә җирне вотчинниклар белән бер үк дәрәҗәдә (җан башына 40 ар дисәтинә) бүлеп бирүне таләп итә башлыйлар.

Кормаш һәм Карач авылларының вәкилләре 1808 елда Оренбург палатасында үз бабаларының хәзер алар хуҗа булып торган биләмәләргә ике гасыр элек үк килеп утыруын исбатларга тырыша һәм карачлылар, дәлил итеп, хәтта бабаларының 1691 елдан башлап 1745 елга кадәр, ә кормашлылар 1723-1747 елларда түләгән ясак квитанцияләрен чыгарып сала. 1687 елда грамота алуга ирешкән Әмәкәй, аларга кушылып һәм шушы ук грамотаны калкан итеп, Уразмәт, Исәнсеф авылы крестьяннары да үзләрен вотчинниклар белән тиңләүне һәм аларның ирләренә дә җан башына 40 ар дисәтинә хисабыннан җир бүлеп бирүне таләп итә. Әмәкәй, Уразмәт, Исәнсеф авылларының үз җирләренә Байлар волостеннан бик күп качакларны кертүен сәбәп итеп, аларның үтенечләрен кире кагалар. Моңа үч итеп, Әмәкәйдәге «башкорт»ларның бер өлеше 1790 елларда Кыр-Елан волостеның Исламбакты авылына, ягъни бүгенге Башкортстан җиренә күчеп китә. 1658 елда Мөшегә елгасы буендагы Имәнче авылында яшәүче Юкәчи Дускаев та үзен сусар тиресе белән ясак түләүдән азат итүләрен үтенеп, Уфа воеводаларына мөрәҗәгать итеп карый, әмма, билгеле ки, ул да үз теләгенә ирешә алмый.

Ничек кенә гаҗәп тоелмасын, җир-биләмәләр өчен дәгъва һәм судлашу ике күрше волость вәкилләре арасында да булмый калмый. 1678-1680 елларда, мәсәлән, Мөшегә белән Ирәкте волосте вотчинниклары арасында тарткалашу туа. Ирәкте волосте "башкорт"ы Каракүз Аканаев Мөшегә авылы татары Акешка (?) Дускаевның Ык елгасы буендагы биләмәләренә борын сузып караса да, Уфа воеводасы П.Д.Скуратов Дускаевка җирнең 1523 елгы хан ярлыгы һәм Иван патшаның 1577 елгы указы буенча беркетелгән булуын онытмыйча, Каракүз үтенечен кире кага. Судта Акешка Дускаев 1523 елгы хан ярлыгына үзенә бабай тиеш булган Дускенә Буләков исеме дә язылган булуын Явыз Иван патша указын күрсәтеп тә дәлилли. Шунда ук А.Дускаев нәселенең Казан белән Уфа калаларына ел саен 33 сусар тиресе, 10 батман бал белән һәм 6 сум акчалата ясак түләп баруы да бәян ителә.

Элек Бүләр волосте составында, бүген Бакалы районында саналган Киләй авылы «башкорт»ы Бикбулат Биккуловның никадәр биләмәгә хуҗа булып яшәвенә генә игътибар итегез: «А та моя вотчина близ реки Белые Ирганыш да Юва арямы Ямады атовъ да над озером Сютлею красной лес сосны да до малой речки Шабизю по речке Ераку до вершины по правой стороне до речки Большей Шабизю, а по большей речке Шабизю вверх по правой стороне до вершины с красным лесом из дубровами, а с вершины речки Большаго Шабизу на вершину речки Терпили и по речке Терпиле по обе стороны з дубровами до речки Сикии, а по речке Сикие по обе стороны до вершины, а с речки Сикии на речку Калмию и по речке Калмие по обе стороны з дубровами на речку Суякей и по речке Суякею по левой стороне до речки Досай и до речки Сарашли з дубровами и с черными лесами да на речку Куляшту, а по речке Куляште до Суни речки и по Суне речке по обе стороны до устья речки Маты с бортными ухожи <…>да с вершины речки Малой Шабиски, где стоит деревня Чиникова на низ по правой стороне до речки Ерык да на речке Заю» (НА РБ. Ф. И-172. Оп. 1. Д. 20. Л. 36, 68-69).

Менә шушы Киләй авылы Акай Күчемов һәм Килмәк Норышев җитәкчелегендә чираттагы милли-азатлык явы башлангач, Бүләр волостеның 500 старшинасы җыйналган үзәк тә булып тора. Алар 1735 елның сентябрь аенда шушында туплана һәм патша хөкүмәте юллаган карательләр гаскәренең башлыгы генерал-лейтенант А.И.Румянцевның мөрәҗәгатен тыңлый. Аны старшиналарга Румянцев юллаган подпрапорщик Овинов укып бирә, ә татар теленә Байлар Сабасы авылы татары Сәгыйт Хәялин тәрҗемә итеп бара. (Игътибар итегез: 1744 елда патшабикә Елизавета Петровна фәрманы буенча Оренбург янындагы Каргалы бистәсенә нигез салачак кеше бу!) Шушы ук Сәгыйт Минзәләдән килгән чакта Бүләр волостеның Әтрәкле авылында тукталган һәм шунда, дистәләргән хатлар язып, якын-тирәдәге барча төбәкләрдән Киләй авылына җыелу турында фәрман тараткан була. Фетнә юлына баскан татар старшиналары, билгеле ки, патша ялчылары каршында сөттән ак, судан пакь булып кыланса да, бу холуйлар китүгә үк Акай әләме янына барып кушылмыйча калмый...

Бүләр волосте вотчинникларының үз җирләренә Казан өязеннән ясә Байлар, Гәрәй, Йәнәк олысларында яшәгән үз туганнарын, үз татарларын сыендырырга урын табуы турында әйттек. 1722 елда Бүләр авылыныкылар, мәсәлән, Казан өязендәге Җөри юлының Сары Елга авылыннан (фетнәдә катнашкан өчен) качып



● Бүләр волостеның 1816 елгы картасы.

килгән крестьяннарны үз җәмгыятьләренә кабул итә. Байсар авылы халкы Җөри юлындагы Сармаш авылыннан качкан бер төркемне – 1714, икенче төркемен 1722 елда үзенә сыендыра. Ләкин яшәешнең икенче, күңелсез ягы да бар бит. Имана җире, чәчүлек мәйдан җитмәгәнгә күрә, Бүләр волосте составындагы бик күп авыллардан крестьяннар үз кузләренә иркен, азат булып күренгән чит-ят төбәкләргә дә күчеп китәргә мәҗбүр була.

1735-1740 елларда булып узган Акай-Килмәк, аның артыннан ук Кара-сакал восстаниеләрендә катнашкан фетнәчеләрне эзәрлекләү башлангач, 1742 елда Бикчәнтәй авылының 7 гаиләсе бүгенге Башкортстандагы Кыр-Елан волосте җирләренә күчеп китәргә мәҗбүр була. Шул ук елда шул ук Кыр-Елан җиренә Кормаш авылыннан – 4, Әмәкәйдән – 1, Исәнсефтән – 3, Качкын авылыннан – 4, Сөякәйдән – 3, Илтимердән 3 гаилә күчеп утыра. Яңа килешү буенча 1756 елда Исәмәт авылы вотчиннигы Бохармәт Дәүләтбаев Калмаш авылыннан «качкан» 7 гаиләне үз җиренә кертә.

1760 елда бүгенге Әлшәй районындагы Торынтаеш авылына Әнәк авылыннан Бүләр волостендагы ясаклы татарлар старшинасы булып торган Мәксут Морзакаев белән бергә 6 гаилә, Пучыдан – 4, Чәчердән – 4, Муханнан – 1, Тат. Бүләрдән – 3, Тузганабикә авылыннан – 3, Мәткәвеш-Тамактан – 3, Бикбаудан – 1, Туердан старшина Уразмәт Йосыпов кул астында – 3, Песәйдән – 1 гаилә күченә. 1762 елда шушы ук Торынтаеш җирлегенә Бүләр волостеннан старшина Минәй Бикбауов кул астындагы – 46 ир-ат, Уразмәт Йосыповка буйсынучы – 17, Сәендек Туктаев кул астындагы – 8, Нияз Ибраев командасындагы – 7, Ураз Дисәтовка буйсынучы 5 ир-ат күчеп китә. Шул вакытта Әнәк авылыннан да 17 ир-ат Торынтаешка күчә (РГАДА. Ф. 350. Оп. 2. Д. 3801. Л. 1187-1193). 1764 елда Пучы авылы да 32 ирен шул ук Торынтаешка озата. 1764 елда Әнәктән Торынтаешка күченгән ясаклы татар ирләренең саны 19 га җитә.

Тагын да яманрагы – Бүләр волостендагы Әмәкәй авылыннан – 4, Карачтан – 1, Кормаштан – 1, Илтимердән – 1, Коллар авылыннан 1 ясаклы татар, чукындырылып, Бакалы янындагы Ногайбәк кирмәненә күчереп утыртыла.

Тарихтан мәгълүм булганча, 1771-1773 елларда Польшада кузгалган милли-азатлык явын канга батырып бастыру өчен Россиядән гаять зур гаскәр озатыла, аның составына 10 командага бүленгән 3000 татар-башкорт җайдаклары да кертелә. Моңа кадәр Бүләр волосте старшинасы булып торган Муса Мөслимов хәрби поход барышында 7 нче команда башлыгына әверелә. 4 нче 300 кешелек командасы Пугачев восстаниесе барышында фетнәчеләр отряды башлыгы булып йөриячәк Кәип Зыятбәтов, 6 нчы командасы – каһарман Салаватның әтисе Юлай Азналин, 10 нчы командасы Минзәлә төбәгендәге барча фетнә отрядларының башлыгына әвереләчәк Качкын Самаров җитәкли. Документларга фәкать «башкорт гаскәре» генә булып кергән әлеге өч мең җайдак белән Башкортстанның бүгенге Балтач авылында гомер сөргән Кулый Балтачев җитәкчелек итә. Бу командалар Уфадан 1771 елның 16 декабрендә, ә соңгысы 1772 елның 4 гыйнварында чыгып китә. Россиянең экспедицион корпусы белән киләчәктә Пугачев явының җәлладына әвереләчәк генерал-поручик А.И.Бибиков җитәкчелек итә. «Башкорт» гаскәре генерал-майор А.А.Урусов командалыгына кертелә. 2000 җайдак 1772 елның 25 августында кабат Уфага әйләнеп кайтса да, 4 нче, 8 һәм 9 нчы командалар генерал-майор Ф.Ю.Фрейман кул астында Казанга күчерелә һәм берничә айдан соң алар Пугачев гаскәренә каршы, карательләр сыйфатында яуга җибәрелә. Ни галәмәт, югарыда телгә алынган шәхесләр Пугачев явы барышында бер-берсенә каршы корал күтәреп сугышачак, кайберләре шул «гөнаһ»лары өчен каторгаларга да озатылачак бит!..

Бу походта Муса Мөслимов кул астында Бүләр волостеннан Яхшый, Сикия, Елан, Мөшегә, Мәсәгут, Сасыборын (Елгабаш), Сәет, Уразмәт, Әтрәкле авылларыннан да җайдаклар катнаша...

1801 елда Оренбург губернаторы барча волость җирләрен межалау, ягъни аларның чикләрен ачыклау турында махсус фәрман чыгара. Шуннан соң, әлбәттә, үзен вотчинник дип атап йөрткән барча ясалма «башкорт» үз биләмәсенә бирелгән грамоталарны чыгарып салырга, үзенең бу җирләргә законлы рәвештә хуҗа булып торуын исбатларга мәҗбүр ителә. Мондый адым, билгеле ки, бер үк волость, хәтта бер үк авыл крестьяннары арасында да дәгъва-ызгышлар чыгармыйча калмый. Үзләренең хокукларын яклап Оренбургның гражданнар палатасына, хәтта губернаторның шәхсән үзенә мөрәҗәгать итүләр арта. Урындагы воеводалар һәм волость старшиналары үзара низагларны ни рәвешле хәл итәргә белми. Ахыр чиктә Оренбург губернаторы генерал-майор Н.Н.Бахметев 1802 елның 16 июнендә 11 нче кантон башлыгы поручик Солтановка мондый күрсәтмә язып җибәрә:

««Жительствующих самовольно на земле, принадлежащей башкирцам Булярской волости, башкирцев же 11-го кантона Енейской волости команды старшины Ильяса Шарипова, а так же байлярцов в 6 дворах; вследствие вашего ко мне представления, что от 17 марта по прошению тех вотчинников булярцов, предлагаю сослать на собственную их землю Енейской и Байлярской волостям подлежащую, и впредь наблюдать, что подчиненные вам башкирцы отнюдь не смели по своевольству своему, оставя собственные земли, поселятся на чужих». Ни гаҗәп, әлеге күрсәтмә үтәлми, бүләр, байлар, йәнәйлеләр үз җирендә элеккечә яшәвен дәвам итә.

(Дәвамы киләсе санда).

XXI гасырга – буш биштәр белән...

«Болганчык еллар. Мөһаҗирләр» спектакле – Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәевнең, 20 ел буена әзерләнеп, ниһаять сәхнәләштерергә җөрьәт иткән әсәре ул. Без әлеге премьераны түземсезләнеп көттек, тик нәтиҗәсеннән генә бер дә канәгать калмадык, чамадан тыш кәефсезләнергә мәҗбүр булдык.

Сүз дә юк, Мәхмүт Галәү эпопеясе – сәхнә вакытының иң күп өлеше бүленгән бер гаилә тарихы да, Сафа белән җирле дивана/суфый Газиз агай сюжетында гәүдәләндерелгән һәм крестьяннарның Рус илендә бәхет эзләвенә корылган «Некрасов контексты» да түгел; шулай ук ул «фәлсәфә пароходы» дип сыйфатланырга өметләнгән, әмма үз динен һәм үз милли йөзен саклап калу өчен авылы-авылы белән ватаннарын ташлап чит җиргә китәргә мәҗбүр ителгән М.Галәү мөһаҗирләренә бернинди мөнәсәбәте булмаган бүгенге көн качкыннары метафорасы гына да түгел. Берничә буын татар укучысы өчен әлеге әсәр – татар халкының язмышы ачып бирелгән зур эпик полотно ул. М.Галәү үз геройларына мәдхия җырлый, ә Ф.Бикчәнтәев исә постмодернистларча аны «мәсхәрәли». Аерма нәкъ менә шунда да инде (хатын-кыз образларын сурәтләүдәге сексизм, персонажлар системасында герой-демиург ир-атның юкка чыгуы).

Әлеге спектакль режиссерның хушлашу аккорды, аның Марсель Сәлимҗанов театры сәхнәсенә ихтирамы билгесе, безнең йөрәкләребез түрендәге Камал театры бинасында баш режиссерның үзенә бер төрле йомгаклау эше, иң мөһим хезмәте булырга тиеш иде. Яңа бина проектларын тасвирлаганда, заманча дәрәҗәдәге ике сәхнәне көткән дәвердә театрның үз репертуарын ничек үзгәртәчәге, яңа бинада бөтенләй үзгә театраль эстетика хакимлек итәчәге турында күп сөйләнде инде. Спектакль тәмамланып, пәрдә ябылган вакытта залдагы халыкка атап әйтелгәндәй яңгыраган «Эх сез, ахмаклар, наданнар!..» сүзләре күңелгә тиде... Әйе, эпопеядәге гаилә темасын күрсәткәндә, сәхнәдә кызыклы табышлар, фаҗигале мизгелләрне бераз җиңеләйтү мөмкинлеген биргән юмор бик күп... Әмма вак-төяккә зур игътибар бирелеп, бөтенлек җуелган. Күрәмсең, татар дилогиясе «чикләвеге»н вату Европа белеменең хәленнән килерлек нәрсә түгелдер! Һәм хикмәт бер дә бүгенге көн цензурасында түгел! Белмәүчеләр өчен, бу – «Болганчык еллар» әсәре... Моны финалда тамашачыларга таратылган «креатив» бүләкләр дәлилли. Тамашачыларга туфрак салынган кечкенә пыяла савыт өләшүче волонтерлардан әлеге «бүләкне» үзләренең ничек аңлауларын сорарга булдым. Спектакль логотибы төшерелгән кара толстовка кигән кызлардан берсе илһамланып төшендереп тә бирде: «Беләсезме, апа, спектакльдә Төркиягә киткән татарлар турында сөйләнә. Менә шуңа күрә дә театр сезгә истәлеккә «төрек җир»ен бүләк итә. Әлбәттә инде, савыттагы туфрак Төркиянеке түгел, Казанныкы гына, курыкмагыз! Аңлыйсызмы, бу бит символ!» – ди. Үз нәүбәтемдә миңа да белгәннәремне сөйләп бирергә туры килде: XX гасыр башында ук Тукайның «Китмибез!» дип язуын, шул рәвешле татарлар өчен үз ватаннарының никадәр кадерле булуын күрсәтүен; мөһаҗирлектә үлгән кеше кабереннән туфрак алып кайтып, аны кендек (ә кендек татарны туган йорты белән мәңгегә бәйли дип санала) каны тамган туган җире туфрагына кушу гадәте булуын; туган җир куәте мосафирны ватанына кире тартып кайтарсын өчен, үзләре белән юлга бер чеметем туган туфрак алу гадәте барлыгын да аңлаттым... Болар барысы да без, татарларның, туган мәдәниятебезне аңлаудан никадәр ерак торуыбызны тагын бер кат дәлилли... Без, чит тенденцияләргә яраклаштырып, үзебез дә сизмичә, аны әкренләп юкка чыгарабыз бит...

Хореографиянең аталы-уллы Батуллалар «ачышы» саналган «хайвани» сексуаль энергетикасы турында... Татар фольклористикасы буенча хезмәтләрне игътибар белән укып чыгыгыз һәм җир-су төшенчәсен русларның «земля-Богородица» мифологемасы белән алыштырудан сакланыгыз. Татарларда борын-борын заманнан бирле куш асыл төшенчәсе яши. Безнең бабаларыбыз Җир атасы (Җирән сакал), Җир анасына (Сылу бикә) ышанган. Ирнең җирне сөрү–«аталандыру» йоласы бераз башка «опера»дан. Нократ ягы татарларында сөлге яру кебек туй йоласы бар, ул яңаның тууы символы булып тора. Яңа тормыш башлануын күрсәтеп, Кендек әбисе тарафыннан да ул шул мәгънәдә файдаланыла. Кәләшнең хайвани энергетикада билбау сүтү күренеше исә тамырларга әйләнеп кайтуны аңлатмый, милли идеалны башка нәрсәгә алмаштыруга әйләнә...

Бездәге ил-ватан асылының ирләргә хас төшенчә булуын онытмау мәслихәт. Сазаган кызларның «кош» асылын ачу исә максатка ярашлы булып чыккан. Татар горефләрендә йорт – чебеш-балалар үсә торган оя ул. Башка көл сибү эпизоды исә аптырашта калдырды. Спектакльдә бу – корылык китереп чыгарган фаҗига билгесе... Мөселман традициясендә исә, шул исәптән татарларныкында да, әлеге йоланың мәгънәсе бүтән... Хакыйкатьне чит мәдәниятләрдән эзләргә кирәкми, бәлки, «Олонхо» театры кебек, милли җәүһәрләрне онытылып барган үз мәдәниятебездә табарга вакыт...

Артистларга ышандыргыч образлар тудырулары өчен рәхмәт! Сәҗидәнең әтисе Йосыф (Илтөзәр Мөхәммәтгалиев), Сафаның әбисе Зөһрә карчык (Алсу Гайнуллина), дивана Газиз агай (Радик Бариев) образлары бигрәк тә күңелгә хуш килде... Ә менә геройларның костюмнары күңелгә ятарлык түгел... Сәнгать бизәлеше кабатлаулардан гыйбарәт... Мәгълүм ки, үзенең элек куйган спектакльләре белән даими диалог әлеге режиссерның фишкасы булып тора. Менә биредә дә «Хуҗа Насретдин», «Банкрот» белән диалог ярылып ята... Ымсындыргыч «Алтын битлек» артыннан куганда, татар театрының үзенчәлеге, аның асылы җуелмауны телим! Премьера белән, кадерле театрыбыз!

Миләүшә ХӘБЕТДИНОВА.
Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА
тәрҗемәсе.

Равил РАХМАНИ

Ябышып йөрмә кемгәдер, Булсын ла үз канатларың...

БЕЛЕМ, ҺӨНӘР

Татар галимнәренә

Җитәр, галим, җилпенергә...
Йолдызлар дип очынырга,
Төпченергә Җиһан серен, –
Фән баскычын куйчы җиргә!
Җиде катлы күкләреңнән
Төш, кире кайт туган илгә:
Җиткер көнгә Иман сүзен –
Сызылсын нур – тузган мидә?!

Төшеп вакыт коесына,
Җитәр, галим, чокчынырга;
Тарих өйгән пычрак ләмне
Күп түктең, чык чынлыгыңа!
Су төбенең зар-өмете
Какланмасын моңы тулып;
Тибеп торсын ил йөрәге
Сөю-нәфрәт җыры булып.

Кырыс гыйлем хөкеменең
Кодрәтен куй һөнәреңә;
Көн үткәрмә кәсепчедәй
Бу үзгәреш көннәрендә.
Курыкмый бас буразнага –
Ерак бабаң эзләренә;
Пакьлә бурыч-гамәлеңне
Әхлак-көрәш кизләвендә.

Кач көнлекче коллыгыннан –
Буш сүз, алдаш базарыннан;
Сиңа Ходай акыл биргән –
Тайма тәкъдир язганыннан.
Җегәрле иткән – кырыс заман
Сынавында тартышырга;
Көпчәксез милләт арбасын
Төптән җигелеп тартышырга.

Юк, баетмас бу һөнәрең,
Аңа исең китмәсен лә...
Илт халкыңны яшәешнең
Әбелхәят чишмәсенә.
Ябышып йөрмә кемгәдер,
Булсын ла үз канатларың;
Җилгәрсен – милли йөрәгең
Тормышның бар кара-агын:

Миллионнарның язмыш ватык,
Беткән илдә аңлы хаклык;
Җитми килеп җир халкына
Сабый җанлы таңгы вакыт.
Кайтар, галим, юлдашларың
Тулы фикер сәләтенә;
Көйлә милли яшәешне,
Кайтар Тукай «Сәгате»нә[1] !

ТЫРЫШЛЫК[2]

(Замана бәхәсе)

– Беләсездер, балалар:
Татлы белем җимешләрен
Үрелеп өзеп алалар!

– Без татарда исәрләр –
Ботагына менеп утырып,
Шул ботакны кисәләр.

– Пычкы уйный кулларда...
Бөтен мәктәп бик канәгать,
Исән аяк-куллар да.

– Безнекеләр тырышлар.
Хисап әзер: «Олы җиңү –
Ботак-ботак[3] уңышлар!»

КҮРШЕ ХАКЫ

Күрше хакы – Алла хакы!
(Татар халык мәкале)

Әни әйтә: «Күршеләр, – ди,–
Үзебездән яхшырак!»
Ә күрше апа безне мактый...
Белмим, кайсы хаклырак?

Күрше – бездән, без күршедән
Дөрестән дә әйбәтме?..
Үз-үзеңнән шәбрәк булу –
Теләктерме, гадәтме?!.

Җирдә шундый күршең юкта
Аянычтыр кешегә;
Күрше хакын хаклап яшәү –
Һәркемне ул үстерә!

Нигә тарих китабында
Талау һәм үлем генә?
Өйрәтсеннәр дәресләрдә
Күрше булу гыйльменә!

Бар милләтләр, бөтен илләр
Булсын әйбәт күршеләр!
Рәхәтләнеп, иркен сулап
Яшәр иде кешеләр!

АНА ХӘТЕРЕ

Кирәк түгел тарих китаплары,
Җаны тулы ядкәр – әйтерә;
Көнен көнгә үрер вакыт җебен –
Йөрәгеңдә аның хәтере!

Күзме мөһим сукыр мәхәббәткә,–
Баласы аша күрде дөньяны...
Нәселенә затлы бүләк итеп
Карынында йөртте ул аны!

Кендек өзгәч, җанын бу тормышка
Бишек җыры белән ялгады;
Белде сабый тәмен яшәүләрнең,
Татлы сөтен имеп ананың.

Дөреслекне ачар теле белән –
Ул булмаса... аңа кем әйтер?!
Аңлы бала – төптән фикер йөртер,
Дәреслекне үзе төзәтер?!

Ана хәт(е)ре – ачкыч килер көнгә,
Күзен төбәп калыр озатып...
Өммәтенә барып куш(ы)лыр бала –
Табар өчен тамыр-йозакны!

Алып керер газиз туган теле
Мирасына ата-бабаның...
Мең авазлы милләт чишмәсендә,
Юк, корымас рухы баланың!

ҖИДЕ БАБАЙ ҺӘМ БЕР ОНЫК...

Ни кызганыч, бабайларның
Күрми калдым берсен дә;
Туган... яшәгән... киткәннәр... –
Калган безгә өч җөмлә!

Их, шул җиде бабай белән
Бүген күрешсәң иде;
«Кара, ничек охшашканбыз!..» –
Дип бер көлешсәң иде!

Ябык елларның хәлләрен
Сорап белешсәң иде;
Милләтнең шатлык-хәсрәтен
Бергә бүлешсәң иде!

Чорның соры тузаннарын
Селтәнеп атсаң иде;
«Бу көнне дә күрдек бит!..» – дип,
Кочып елашсаң иде.

Гасырларны алып учка,
Төбәлеп баксаң иде;
«Җиңдек-алдадык!» дигәннең
Мәкерен ачсаң иде.

Көчләп тагылган тарихтан
Чынлыкка кайтсаң иде;
«Без башка юлдан!» дияргә
Зур кодрәт тапсаң иде.

Ничекләр алга барырга
Ныклап киңәшсәң иде;
Дөньяның бөтен татары
Мәңге берләшсәң иде!

Бер йодрыкка төйнәлгәнне
Дошман да күрсен иде;
Безгә дә бәхет килгәнгә
Дөнья сөенсен иде!

Янда тәмле чәйләр ясап
Әбиләр йөрсен иде:
«Бәбкәм, барча оныкларны
Чак(ы)рып кил!» – дисен иде.

БАТЫРЛЫК

(Бабай һәм онык)

– Бабай, элек сөйли идең
Яуда, сугыш кырында
Ятып калган милләттәшләр –
Каһарманнар турында:
Дзотларны каплаганнар,
Танкларда янганнар;
Әсирлеккә эләккәч тә
Батыр булып калганнар...
– Әйе, улым, сугыш та юк,
Сугыш кебек узган юл;
Җанисәптә ни өчендер
Татар кими елдан-ел...
– Ничек, алар бер җавапсыз
Яшәүдән курыкмыймы;
Тере чактук үлем яулау
Ул шулай зурлыкмыни?
Йөрәкләрдә түгелмени
Үзең саклау коралы;
Тыныч көндә кими барган
Милләт батыр буламы?!.

* * *

Бу гомерне сорап алмаганмын:
Насыйбы шул... мәкер, элмәкләр;
Чәбәләнеп бетәр иде башка –
Ярый, димен, миңа эләккән!

Дөнья белән кырыс алыш-биреш,
Үзгә хисап сабый яшемнән:
Таңда кояш көлде үги булып...
Җиргә күзем ныграк ачылган!

Ак-караны аерыр җан биргәнсең,
Ау төенен чишү әмәле;
Тамчы суда кояш күрү дәрте,
Утлы мәхәббәтен галәмнең.

Зур сөюнең үсмер вәгъдәләре,
Якты көндәй сүнде – ай калды;
Күлдә бәгъре кара көйгән җикән,
Кырда рәшә-өмет чайкалды.

Меңгә телде гомер җилгәргече
Аямыйча дусны-дошманны;
Әмир итте никтер ул куштанны –
Боерып яши нәфсе кушканны.

Ике башлы комсыз үрмәкүчнең
Тозагына халык эләккән;
Ничә гасыр чәбәләнә, бахыр,
Коллык йөген тартып элмәккә...

Бу гомерне сорап алмаганмын,
Ул тәкъдирдә сайлап бирелгән:
Милләт күрке – акбүз бала идем,
Чыгалмадым тормыш төбеннән.

Тыз-быз килеп заман куа арттан,
Төпкә җиккән миндәй җүләрен;
Өч шагыйрьлек гомер-язмыш бирдең, –
Бу әҗерне ничек түләрмен?

БЕРЕНЧЕ ГЫЙШЫК ХАТЫ

Татлы исеме ачар иртәләрең,
Якты рәсеме тартып торыр кичен...
Айлар, еллар кайнап тулган хисең
Телдән әйтеп биреп булыр димсең?!.

Кирәк каләм, йөрәк, йокысыз төн –
Чумар өчен җанның чоңгылына:
Алып чыгып энҗе-мәрҗәннәрен,
Таҗ куярга яшәү чынлыгына!

Гашыйкларның мәгълүм кыюлыгы:
Гади хатка күч(е)реп бар халәтен,
Мең җай табып үтеп керер чикне
Тапшырырга йөрәк әманәтен!

Күңел кошын, мең кат әфсен укып,
Чыгарып да мең кат биктән ачып –
Гашыйкларның мәгълүм куркаклыгы:
Көтәр хөк(е)мен ялгыз читкә качып...

Төн йоклатмый җаннан саркып тулган –
Пешеп җиткән йөрәк җимеше ул;
Каурый болыт – хыял дәрьясының
Ләйсән яңгыр булып җиргә иңеше ул!

Ап-ак кәгазь, ике очкын җөмлә –
Йөрәкләргә ялкын үрләтерлек;
Сөю хаты – утлы рапсодия,
Язмышларны борып үзгәртерлек!

Ул чакыра парлы очышларга!
Гомерлеккә салыр януларга...
Канат җәеп горур күккә менәр,
Җилгә очар... тузгып каурыйларга.

---

[1] Тукайның «Ваксынмыйм» шигыренә ишарә.

[2] Кайчандыр татар халкын үлемнән йолып калган аның ихлас тырышлыгы бүгенге вәзгыять шартларында үзенә кирегә эшли – ел саен мәктәпләрдә йөз меңләгән татар баласы туган телен, димәк, төп яшәү фәне агачын корытып, телгә дошман, ата-баба рухы һәм аның культурасына битараф манкортка әверелә.

[3] Поэтик тәрҗемәдә моны «Күсәк-күсәк уңышлар!» дип аңларга кирәк *(автор искәрмәсе)*.

Чуашстан татарлары янында кунакта

Күптән түгел «Ак калфак» татар хатын-кызлары оешмасы Чуашстанның Тукай, Татар Согыты, Урмай, Шыгырдан авылларында үткәргән утырышта гореф-гадәтләребезгә, балалар тәрбиясенә кагылышлы мәсьәләләр күтәрелде. «Өч буын тәрбиясендә туганлык мантыйгы» дип исемләнгән җыенда аккалфаклылар үрнәк итәрдәй эш-гамәлләр күрдек.

Россиянең 13 төбәгеннән килгән 60 лап кунакны республика чигендә Чуашстан татар хатын-кызларының «Ак калфак» оешмасы рәисе Сания Ишмуратова җитәкчелегендә җыр-моң, чәкчәк белән каршы алдылар.

Беренче тукталышыбыз – Комсомол районының Тукай (Токаево) мәхәллә йорты. Авылның ике-өч катлы йортлары, бизәкле тимер капка-коймаларына хәйран калып торырга да өлгермәдек, Чуашстан татар милли-мәдәни мохтарияте рәисе Марат Айзатуллов эшлекле сөйләшүне башлап та җибәрде. Ә мәхәллә йортына аккалфаклылар белән очрашуга Тукайның ак яулыклы әбекәйләре җыелган иде.

Чуашстан татарлары дин белән милләтне бүлми. Совет заманнарында күрше республикада халкыбыз дин кушканча яшәвен дәвам иткән, ике мәчет эшләп торган, аларның берсе әле дә сүтелмәгән. Корбан да чалганнар, ураза да тотканнар, яшьләргә милли тәрбия бирү ысулларын да тапканнар. Бүген Тукайда 2 меңнән артык кеше гомер итсә дә, клуб юк. Мәхәллә йорты клуб та, халыкның җыелу урыны да булып тора, барлык киңәш-табыш итәрдәй мәсьәләләр шунда хәл ителә. Биредә яшәүчеләр күмәк хуҗалык банкротлыкка чыккан вакытта да, бергә җыелып, җирләрне пыран-заран китерергә юл куймаган, барысын да бергә туплап, мәхәллә йортына тапшырган. Теләгән кешегә 60 сутый җир бүлеп бирелгән, калганын көтүлеккә, башка чыккан кешеләргә калдырганнар. Печән мул булгач, малны да күп асрыйлар. «Без балык бирмәдек, кармак тоттырдык», – ди авыл җирлеге рәисе Әгъзәм Шакиров. Бу як татар авылларында ир-атларның хәтсезе – ит бизнесында. Малны сату авыр түгел, Тукайда хайван чалу өчен алты цех бар. Алардан ит Россиянең төрле шәһәрләренә озатыла. «Бездә ир-атлар – 60-70 меңсез, хатын-кызлар 30-40 меңсез эшкә бармый», – ди Әгъзәм хаҗи. Алга таба Татар Согыты, Урмай, Шыгырдан авылларында да Тукайдагы кебек үк тәртипләр куелганлыгы аңлашылды.

Йортларыннан ук күренгәнчә, Чуашстанда яшәүче татарлар тырышлыгы белән аерылып тора. Авылда мәчетләр, мәхәллә йорты да эшләп килә, бер нигездә элеккечә әби-бабай, әти-әни һәм балалар яши. Бу як татарларында кайнаналык, кайнаталык саклана, бер йортта ике яки өч гаилә гомер итә. «Килен кеше иренең атасы каршында беләкләрен, чәчен-башын ничек ачык йөртсен? Хатын-кызлар әле дә мәчет каршында авызларын яулык белән каплый, Галимҗан абзыйның җәмәгате Мөнзилә апа, мәчеттән ир-атлар чыкканда, яулыгы белән битен үк каплап куя», – ди Наил хәзрәт. Очрашуда катнашкан Гөлчирә Шәйдуллина да улы-килене, оныклары белән бер нигездә гомер кичерә. «Без Чуашстанда яшәсәк тә, үзебезне Татарстанның бер өлеше итеп сизәбез, «ТНВ-Планета» телевидениесен карыйбыз. Татар дөньясының һәр почмагын күрәбез. Берәр спорт ярышында татар командасы булса, җиңү теләп утырабыз», – ди ул.

Советлар вакытында Тукай бүгенгедәй мәртәбәле авыл булмый әле, 1990 елда анда 298 шәхси йорт булуы теркәлеп калган. 30 елларда авыл ике тапкыр диярлек үскән, хәзер анда 500 дән артык шәхси хуҗалык бар. Җирлек зурая, халкы ишәя тора. Яшьләр авылны ташлап китми, махсус яки югары белем алырга Казан, Чабаксар ягына юл тотканнары да туган җирләренә кайта. Берничә ир туган үсеп җитешкән өйләрдән, башка чыгып, яңа йорт тергезүчеләр дә хәтсез. 1990 елда мәчет тә яңадан төзелгән.

Мәгълүм ки, Финляндиядә яшәүче татарлар үзләренең мәхәллә системасы белән танылды. Тукайлылар да, аларның да тәҗрибәсен өйрәнеп, үзләрендә мәхәллә системасын торгызыйк, дигән ният тә, иҗтимагый киңәшмә оештыра. Анда ай саен җыелып, авылда килеп туган мәсьәләләрне тикшерәләр, аларны хәл итү юлларын эзлиләр. Юлларны ремонтлау, белем бирү өчен яңа белгечләр эзләү һ.б. шундый мәсьәләләрне уртага салып сөйләшәләр, матди ярдәм таләп ителсә, булышмыйча калмыйлар. Үзләренең «Нурлы иман» газетасы чыга, сайтларын да булдырганнар. Хәзер төп игътибарны балаларны тәрбияләүгә бирүне, аларга дини гыйлем өйрәтүне бурыч иткәннәр. Эшне мәдрәсәләрендә балалар өчен җәйге лагерь оештырудан башлаганнар. 2006 елдан бирле балаларның мәдрәсәдә укуын ел әйләнәсендә алып баруны оештырганнар. Балалар, мәктәптә дәресләр тәмамлангач, гыйлем алырга мәдрәсәгә юнәлә. 2007 елда хәзрәтнең Төркиядә белем алып кайтуы да эшләрне җиңеләйтә. Тора-бара балалар гына түгел, совет заманында үсеп җитешкән өлкәнрәкләр дә мәдрәсәгә йөреп гыйлем эсти башлый. Алар авылның түбән өлешендәге мәдрәсәдә белем алганнан соң, укуларын мәхәллә йортында дәвам итә. Мәчет янындагы мәдрәсә гөрләп эшли, анда100 дән артык бала белем ала.

Кызларның яулык бәйләвенә бәйле хәлләр дә булган. Әгъзәм әфәнде бу уңайдан бер вакыйганы да искә төшереп үтте. Кыз балаларның 80-90 проценты мәктәптә яулык белән йөри торган була. Аңлашыла ки, бу авыл кешеләренә бик ошый, алар моның белән мактанып алырга да ярата. Укучылар арасында, белем дәрәҗәләрен тикшереп, конкурслар үткәрәләр, иң көчлеләрне бүләкләр белән зурлыйлар. Бу тантана, гадәттә, мәчет янында үтә. Мәктәпкә Чуашстанның мәгариф һәм фән министры Галина Чернованың киләсе билгеле булгач, бүләкләүне уку йортында үткәрик, дип килешәләр. Бәйрәмгә мөфтине дә дәшәләр. Тантана ишек алдында үтәргә тиеш. Урамда 30 градус эсселек. Балалар тезелеп баса, кызлар барысы да яулык-күлмәктән, мөселман чалбарыннан. Аларга бүләкләр бирәләр. Министр рәхмәт әйтеп китеп бара. Әмма... Мәктәп, авыл җитәкчеләрен икенче көнне үк прокуратурага дәшеп алалар, бу эш ике елга сузыла. Балалар мәдрәсәдә дә, мәктәптә дә яхшы укый, «бишле»гә генә тәмамлаучылар да хәтсез. Алар алтын медальләрен алу өчен район үзәгенә барырга тиеш. Кызларны, яулыгыгызны салмасагыз, медаль бирмибез, дип кисәтәләр. Әмма кызлар яулык белән бара, ә медальләрен барыбер тапшы-

● Тукай гомуми белем бирү мәктәбенең «Робототехника» түгәрәгендә.

● «Мишәр» ансамбле кунак каршылый.

Асылыбызга кайтып барышлый

● Нәҗия әби Миннегалиева станокта палас туку серләрен бик күп яшьләребезгә өйрәткән.

● Тукай авылының ак яулыклы әбиләре.

ралар. Алар алга таба югары уку йортларын тәмамлый...

Тукай урта гомуми белем бирү мәктәбендә дә әхлаклы балалар тәрбияләү үзәккә куелган. Биредә 348 бала белем ала. Берочтан шунысын да әйтик, бу көнне аккалфаклылар булган татар авылларының барысында да I-IV сыйныфларда балаларга белем татар телендә бирелә, рус теле дәресләре генә шуларча бара. Татар теле һәм әдәбияты дәресләре атнасына өч сәгать исәбеннән 11 сыйныфка кадәр укытыла. Укучыларның тәнәфесләрдә Татарстандагы байтак татар мәктәпләрендәгечә үзара русча аралашмавы, туган телләрен үз итүе дә күңелгә сары май булып ятты.

Белем учагында балалар саны елдан-ел арта. Атнасына биш көнлек уку программасы. Башлангыч сыйныф укучылары әле чәршәмбе, шимбә һәм якшәмбе көннәрендә мәдрәсәгә, әхлакый тәрбия дәресләренә дә йөри. Директор Наил Зарипов тарих дәресләрендә, тәрбия сәгатьләрендә еш кына нәсел тамырлары мәсьәләсе күтәрелүе турында сөйли, укучылар кызыксынып үз шәҗәрәләрен ясый. Балалар укуда да сынатмый, ел саен Казанда үтә торган татар теле буенча олимпиадаларда лаеклы урыннар алып кайта. Төрле темаларга үтә торган конференцияләрдә дә тукайлылар чыгышы югары бәяләнә. Шул ук вакытта мәктәптә сәнгатькә дә игътибар зур. Әйтик, уку йортында театр сыйныфлары бар. Күптән түгел Буа шәһәрендә үткән «Ният» балалар театр коллективларының төбәкара фестивалендә 78 команда арасында Тукай балаларының иҗаты беренче урын белән бәяләнгән. «Укытучылар «Иң яхшы класс җитәкчесе», «Ел укытучысы» кебек профессиональ конкурсларда да лаеклы урын ала», – дип сөенә директор.

Тукай мәктәбендәге «Туган як» музее, «Робототехника» секциясе, «Салават күпере» мәктәп телевидениесе эшчәнлеге дә сокланырлык.

Киләсе тукталыш – татар мәдәнияте үзәге буларак танылган Урмай авылы. Бу – 3200 дән артык кеше яши торган, мең шәхси хуҗалыклы, өч мәчетле авыл. Кунакларны авыл мәдәният йорты җитәкчесе Илсөяр Зыятдинова җитәкчелегендә Фәрит Гыйбатдинов исемендәге «Мишәр» халык фольклор ансамбле каршы алды. Шунда ук ике күргәзмә дә куелган. Ул авылның элекке заман белән бүгенгесе бердәмлектә булуын исбатлый. Күргәзмә бу як татарларына гына хас йорт эчен, кул эшләрен тасвирлый. Шунда ук станокта палас тукып утыручы Нәҗия әби Миннегалиева белән танышабыз. Ул кечкенәдән үк тукуны үз иткән, хәзерге яшьләргә дәресләр бирә. Ул – Фәрит Гыйбатдиновның әбисе, хатыны Вәгыйзәнең энисе.

Урмай авылы үз тарихын XVII гасырда башлап җибәрә. Монда өч ир-ат патша гаскәрләреннән качып килә. Аларның берсе Урмай исемле була. Тиз арада Урмай җирендә хуҗалыклар саны йөзгә җитә. Бүген авылда 157 еллык мәктәп, 110 урынлы «Ләйсән» балалар бакчасы бар. Мәдәният үзәгендә Батыр музыка-сәнгать мәктәбенең филиалы эшләп килә. Анда балалар курайда, гармунда уйнау осталыгы серләренә төшенә, татарча җыр-биюләрне өйрәнә. Филиал ярдәмендә «Мишәр» ансамбленә дә кадрлар әзерлиләр.

«Мишәр» ансамбленең 40 еллык тарихы бар. Фәрит Гыйбатдинов, Борнар авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлап, авылга кайта. Әмма күмәк хуҗалыкта эш табылмый. Рәис белгечкә вакытлыча мәдәният йортында эшләп торырга куша. Ә ул Ф.Гыйбатдиновның гомерлек эш урынына әйләнә. Егет башаягы белән мәдәният дөньясына кереп чума. «Мишәр» ансамблен дә Фәрит тамырландыра, мәктәпкә, райондагы төрле оешмаларга бара, укучылар, укытучылар арасыннан җырчы-биючеләрне сайлый. Шулай итеп коллектив туплана, ул тора-бара данлыклы ансамбльгә әверелә. Коллективның төп максаты исә – борынгы җырлар, борынгы биюләрне кайтару. Шушы нияттән, онытылган халык җырларын, йолаларны өйрәнеп, коллектив белән берлектә халыкка җиткерәләр. Ансамбль Чуаштандагы башка фольклор ансамбльләреннән дә аерылып тора. «Казаннан читтәрәк гомер итсәк тә, бу якта милли үзаңлы, динле, гореф-гадәтләрне саклап калучы иҗади халык яши», – ди Илсөяр Зыятдинова. Бүгенге көндә ансамбль өч төркем белән эшли. Күп кенә яшьләр шушы ансамбльгә йөреп, алга таба Казан һәм Чабаксарның мәдәният һәм сәнгать уку йортларында белем алган. «Мишәр» ансамбле – Чуаштанда бердәнбер татар халык фольклор коллективы. Ул Татарстан галимнәре, мәдәният әһелләре белән даими элемтәдә тора. Шушы уртак хезмәтнең нәтиҗәсе булып 1998 елда Татарстан җыр һәм бию ансамбле тарафыннан шушы якка гына хас булган мишәр биюе сәхнәләштерелә, «Казан» җыр һәм бию ансамблендә «Урмай болыннары» композициясе куела. Ансамбльнең тагын бер үзенчәлеге – коллективтагы үрнәк гаиләләр. Фәрит Гыйбатдиновның җәмәгате Вәгыйзә, кызлары Динә, оныклары Сәид бергәләп ансамбльдә иҗат итә. Татарстанның атказанган артисты, ансамбльнең музыка җитәкчесе Илдус Шәйдуллин да кечкенәдән «Мишәр» коллективы белән бергә авылларда концертлар куеп йөргән, аннары белем алуын Казан мәдәният һәм сәнгать академиясендә дәвам иткән. Хәзер инде улларны Йосыф белән Илданны сәнгать юлына кертә. Алар «Мишәр» ансамбле белән төрле конкурсларда катнаша, Россиянең төрле төбәкләрендә сәхнәгә чыга, хәтта Төркиядә дә булып кайтканнар.

Сәнгать җитәкчесе Илнар Хисамовның әнисе Мингафа да – «Мишәр» ансамбле җырчысы. Гомер буе штукатур-маляр булып эшләгән ханым үзенең яраткан шөгылен ансамбльдә тапкан.

Ансамбльнең җитәкчесе Илсөяр Зыятдинованың әнисе Гөлсирә Арифуллина «Мишәр» ансамблендә беренче буын булса, ул үзе өченче буын. Хәзер инде кызы Айзилә Зыятдинова да шушы иҗат коллективында...

Өченче тукталыш – Татар Согыты авылы. Биредә мәктәпнең 100 еллык юбилеен үткәрү уңаеннан ачык һавада музей эшләп куйганнар. Мәйданчыкта авыл халкы ярдәмендә бай материал тупланган.

171 бала белем ала торган мәктәптә Батыр музыка мәктәбе филиалы да эшли. Уку йортында көрәш, волейбол секцияләрендә, һ.б. спорт төрләре белән шөгыльләнәләр. Физкультура укытучысы Фәнис Әхмәтов укучыларның республика, хәтта Россия күләмендә җиңү яулаулары белән горурлана. Бу көннәрдә генә Чабаксарда үткән татарча көрәш бәйгесендә икенче урынны алганнар. Зурлап балалар Сабан туе үткәрү дә гадәткә кергән. Сабан туе батырына тәкә бирелә. «II-III сыйныф укучысы тәкә алып кайтса, авылда аннан да «зуррак» кеше юк инде ул», – дип шаярта үзе.

Мәктәпнең Туган якны өйрәнү музее, Бөек Ватан сугышына багышланган стенд, яу кырыннан кайтмый калган 219 кешенең ак торналарга әверелеп очуы тәэсирләндерә. Хезмәт кабинетында ризык пешерергә өйрәнгәндә дә, музыка уен коралларында осталыкны шомартканда да, шахмат уеннарында чарланганда, тегү-чигү, бәйләүгә өйрәнгәндә дә укучыларга ярдәмгә үз эшенең осталары булган авылдашлары килүе – гадәти хәл. Ә инде өлкәннәргә компьютер ярдәмендә хезмәт күрсәтү соралса, аларга мәктәп ярдәм итә.

Уку йортында 2005 елдан драма түгәрәге эшли. X һәм IV сыйныф укучылары аерым төркемнәр булып, сәхнәгә бер генә чыкмаган. Укучылар уйнавында Туфан Миңнуллинның «Гөргери кияүләре»н күрергә насыйп булды. Алар бу спектакльне «Ният» фестивалендә күрсәтеп, призлы урын да алган...

Соңгы тукталыш – Шыгырдан. Бу – Россия күләмендә иң зур татар авылы. 6200 кеше яши. Авылда ике урта мәктәп, 160 ар урынлы ике балалар бакчасы. Барысы да тулган. Яшьләр авылдан китми, Шыгырдан көннән-көн үсә бара. Хәзер инде ул ак каланы хәтерләткән салага әверелгән. Күп балалы гаиләләрнең генә дә исәбе 200 гә якын. Аларга җир кишәрлеге бирү өчен яңа микрорайон ачканнар. Шыгырданны эшмәкәр, булдыклы егетләре данлый, алар авылга булыша. Биредә 180 нән артык фермер хуҗалыгы бар. Ит җитештерү цехлары, май заводы, профнастил, брусчатка кебек төрле төзелеш материалларын җитештерү предприятиесе һ.б. гөрләп эшли. Бу як татарлары дин белән милләтне бүлми. Барлык эш-гамәлләр Диния нәзарәте белән берлектә хәл ителә. Дин әһелләре иҗтимагый тормышта да актив катнаша. Шыгырданда гына да 8 мәчет бар.

Кунакларны Чуаштан мөселманнары Диния нәзарәте җитәкчесе Мансур хәзрәт Хәйбуллов «Мөслимә» комплексы капкасы янында каршы алды. Биредә Казандагы «Туган авылым» кебек комплекс булдырырга ниятләгәннәр. Авылдашлары Минсәет Күпкәнев, хатыны вафат булгач, мәчет салырга теләгән. Меценатның әнисе Миңзифа апа – авылның абыстае. Биредә «Миндания» исемендәге кунак йорты бар. Аңа Минсәет әфәнденең бертуган апасының исеме бирелгән. Кунак йортының мәҗлесләр үткәрү өчен аерым кухнясы бар. Бу биләмәдә шулай ук «Чуаштанда – ислам дине» музеен булдырырга ниятлиләр. Агачтан Аллаһ йортын торгызганда, Чуаштанда элеккегедән сакланып калган, әмма 1992 елда ут чыгып янган мәчетнең барлык архитектура элементларын кабатларга тырышканнар. Ул – Әби патша фәрманы белән расланган бер типтагы проект булган.

Шыгырданда узган утырышта Сания Ишмуратова төбәктә гореф-гадәтләребезне саклау ниятеннән күп кенә чаралар үткәрелүен, барлык эшләрне дә Диния нәзарәте белән берлектә алып баруларын билгеләп үтте.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

Рашат НИЗАМИ

Шахмат дәресләре

Без аның белән классташлар идек. Бергә укыдык, чирәмнәрдә бергә тәгәрәп-уйнап үстек, агач кылыч белән тыкрыктагы кычытканнар гаскәрен тураладык. Мин аның бала чактагы «портрет»ын яхшы хәтерлим: түгәрәк йөз, тукмак борын, төптән таза-йомры малай. Яшермим, укыганда минем «икеле» билгесе эләктергән чаклар да булмады түгел. Ләкин аның күбрәк «дүртле» һәм «бишле»гә укуын һич тә уңайсызланмыйча, көнләшмичә әйтә алам. Математика дәресләрендә теләсә кайсы мәсьәләне чикләвек урынына ватар иде ул. Безне, үз тирәсенә туплап, футбол-хоккей ише уеннарга якынайтты, йоклап яткан һәвәслекләребезне уятты.

Ярый, болары сүз башы шикеллерәк килеп чыкты бугай. Ә бит минем сүз сөрешем, әйтергә теләгәнем бөтенләй башка иде. Шахмат йөрешләре, шуның кайбер серләре турындагы фәлсәфә дип әйтимме...

Әйе, бишенче сыйныфта укыган чакларда микән, Шакирҗан дустыма тәмам шахмат җене кагылды. Әтисе алып биргән шахмат тактасы һәм андагы эреле-ваклы хикмәти фигуралар белән ул көннәр буе диярлек әвәрә килде, шушы борынгы уен серләрен өйрәнде. Чирәмдә уйнауларны онытты, еш кына мине дә шахмат тактасындагы лабиринтлар дөньясына «өстерәп» кертә иде. Җавапсыз калмадым: көннәрнең берендә әтием миңа да шахмат тактасы бүләк итте, аның эчендәге фигуралар төшемә кереп йөдәтте.

Вакыт булганда, билгеле инде, шахмат тактасын уртага салып, Шакирҗан дустым белән кара-каршы утырабыз. Безнең арада каты гына көрәш башлана: шахматта кем җиңәр дә, кем беренче булыр, янәсе... Ә кемнең беренче буласы килмәс икән? Оят булса да дөресен әйтим, икәү уйнаган шахмат ярышында мин аны фәкать бер тапкыр җиңә алдым. Анда да ничек диген әле... Бик тә җиңәсем килде! Ул күрмәгән арада, форсатын туры китереп, тоттым да тактадагы кара пешкасын чәлдереп, үземнең якка авыштырдым. Ничектер күрми калды ул моны. Мин җиңдем. Хәрәм гамәл кылуыма артык пошынмадым шикелле.

Минем бу гөнаһсыз хатамны укучы гафу итсен. Хикәятемне алга таба дәвам итәм.

Дустым Шакирҗан, төрле ярышларда катнаша торгач, мәктәп чемпионы гына түгел, тора-бара район күләмендә дә беренчелекне яулый башлады. Берсендә аны хәтта Казан ярышларына да алып киттеләр. Күз тимәсен, «егетебез» үсә, чарлана, дан яулый. Ничек инде моңа шатланмыйсың! Көнләшү дигән нәрсәнең әсәре дә юк бездә. Без бит җир кешесе – крестьян канынан: тиреслектә үсеп тә башын югалтмаган табигать баласы...

Ниһаять, унынчы классны тәмамларга җыенабыз. Шушы көннәрдә безнең кулларга өлгергәнлек аттестаты тапшырачаклар. Нәрсәгә өлгергәнлек? Тормышкамы, егетлеккәме? Моңа кайтарып кына җавап бирүче булмады ул чакта. Боларның берсе дә түгелдер, мөгаен. Без әле хәзергә түтәлдәге өлгереп җитәр-җитмәс ялтырап торган кәбестә кебегрәк булганбыздыр. Күпләребез кая барырга, нинди юлны сайларга белми.

Шакирҗан белән безнең исә максатлар ачык иде: мин университетка, әдәбият-тарих үрләрен яуларга киттем, Шакирҗан авыл хуҗалыгы институтын сайлады. Имтиханның кырлы-сырлы баскычларын үтеп, икебез дә белем сараена кердек. Безнең бәхеткә, ул чакларда әткәң-әнкәң үстергән тана яисә сыерны сатып, шуның акчаларын кемгәдер төртеп укырга керү дигән алама тәртипләр юк иде әле...

Без, ике студент, Шакирҗан белән очрашып торабыз. Тулай торакның кысынкы бүлмәсен киңәйтеп, еш кына шахматка ябырылабыз. Шундый очрашуларның берсендә ул миңа мондыйрак сүзләр сөйләп китте:

– Беләсең ич, дускай, шахмат тактасындагы гади генә пешка, финишка барып җитә икән, көчле-куәтле ферзьгә әверелә. Шахмат уенының төп хикмәте менә шуңарда... Теге чакта син, минем бер пешканы чәлдереп, җиңүгә ирештең. Үпкәләмәдем, бер сүз әйтмәдем. Чөнки синең эчке максатыңны мин аңлаган идем. Так что, шахмат тактасында гына түгел, кешегә тормышта да ферзьгә кадәр барып җитү мөмкинлекләре бар бу дөньяда...

Күрче син аны: сабырлыгы җитеп, ничә еллардан соң минем кабыргага үпкәсез-нисез генә төрттереп куйсын әле! Аның бу сүзләреннән соң баштарак уңайсызланып калдым, аннары гына акылым ул әйткән фикернең мәгънәсен эшкәртергә тотынды. Әйе, шахмат тактасында гына түгел, тормышта да дөнья безгә бик күп мөмкинлекләрен әзерләп куйган: максатың зур һәм үтәлерлек булсын, юлындагы киртәләрне ерып гел алга бар, сөрлекмә! Кулыңа килеп кунган форсатны ычкындырма!..

* * *

Миңа калса, Шакирҗан шахмат турындагы гыйбрәтле фәлсәфәсен әйтеп-сөйләп кенә калмады, ул моны үзенең тормыш-яшәеш мисалында да раслап күрсәтте.

Авылларга да үзгәртеп кору җилләренең килеп кагылган чагы. Колхозлар аягында басып тора торуын, шул ук вакытта яңа бер агым – фермерлыкка да «яшел ут» кабыздылар: кредит ал, эшлә, авыл хуҗалыгын күтәрүгә ярдәм ит! Мәсьәлә якынча әнә шулайрак куелган иде шикелле.

Сабан туйлары батыры, шахмат чемпионы, япь-яшь фермер Шакирҗан эшне дүрт гектар җир алудан башлап җибәрде. Трактор белән үзе сукалады, үзе комбайнга утырды, урган-суккан ашлыгының иң күп өлешен дәүләткә, элеваторга тапшырды. Ниләр генә эшләсә дә, җир кешесе булып калды, маңгай тире белән җирне сугарды.

Бервакыт аның белән мондый хәл булды. Бурадай гәүдәле К–700 тракторы белән үзенең кишәрлегендә буразналар ярып бара иде, гомер булмаганны, пыяла тәрәзәләр каршында ялгыз бер тургай оча-куна өзгәләнә, бәргәләнә... Туктады Шакирҗан, күрде һәм аңлады: алдарак кына тургай-кошның бала тибәр оясы бар икән! Ызанның чүп-үлән каплаган аулак бер почмагында. Бала чыгарырга җыена икән, бәгырь. Әнкә кош үзенең биләмәсен әнә ничекләр саклый. Үзенең газиз баласын ташлап киткән шәфкатьсез аналарга, хатын-кыз исемен йөртүчеләргә гыйбрәт итеп күрсәтәсе иде моны...

Әлеге күренешкә таң калган фермер Шакирҗан тимер сукасын күтәртте дә гөнаһсыз кош оясын әйләнеп узды. Ялан кырда, ялгыз утрау сыман, бер колач киңлеге тырпаеп калды...

Кечкенә чакта әтисенең Шакир атлы улына ничәмә мәртәбә әйткәне булды: кош оясына, бигрәк тә йомыркаларына кагылырга ярамый, читләр кулы тидеме, кошлар үз оясын ташлап китә.

Әтисенең тагын шуны да сөйләгәне бар: атасы Мөбарәкнең яшәр йортын-оясын революция җилләре пыр тузгытып ташлаган икән...

* * *

Әйе, бабасы Мөбарәккә үз оясын – туган йортын, нигезен ташлап китәргә туры килә. Авылның кибет һәм умарта тоткан данлыклы кешесен, кулак чутына кертеп, Себергә сөрәләр. Аның хәтта кайда, ничек үлгәне дә мәгълүм түгел.

Тиктормас һәм үҗәт Шакирҗанның тамыр төпкелендә бабасыннан, абруйлы нәсел-нәсәптән килә торган кызу кан ага иде. Аның куллары гына түгел, бөтен тәне-гәүдәсе гүләп, эшкә сусап тора. Менә шуңа да, бер дә икеләнеп-куркып тормыйча, яңа заманның яңа көннәрендә фермерлык юлын сайлады ул.

Әмма үзе теләп алган дүрт гектар җир шулкадәр мәшәкатьле булып чыкты ки, сөрәсе, сугарасы, ашлыкны урасы, булган уңышны урнаштырасы да бар бит – боларны ялгыз башың гына ерып чыгу берничек тә мөмкин түгел. Кул алмашка эшчеләр, ярдәмчеләр кирәк. Аларны каян аласың? Читтән түгел, билгеле, фәкать авыл кешеләреннән эзләп табарга кала. Шакирҗан нәкъ шулай эшләде дә инде. Ләкин аның бу гамәле читтән яңарак кына эшкә дип килгән колхоз рәисе Хөснуллага бер дә ошамаган икән.

Сәгате сугып, колхоз идарәсендә икәүдән-икәү, күзгә-күз очраша алар.

– Колхозда болай да кул көчләре җитми. Ә син минем кешеләрне үзеңнең шәхси хуҗалык эшләренә тартасың, – дип, сүзне текә генә башламакчы булды яңа рәис.

Кара син аны, минем кешеләр, дип сөйләшә бит, кызыл авыз! Шакирҗан көлемсерәде баштарак, аннары тыныч кына җавап бирде:

– Ә син аларга вакытында хезмәт хакы түли аласыңмы соң?

Яшь председатель, борчагы пешмәгәнгә борчылып, сүзне икенче якка борырга тырышты:

– Шапырынма. Арендага җир алган өчен үзеңнең түлисең бар әле.

– Борчылма. Вакытында түләрмен. Договор көчендә кала.

– Акчаны вакытында түләмәсәң, син колхоз җирләреннән колак кагачаксың.

– Куркытма, – диде Шакирҗан, һаман да тынычлык саклап. – Әгәр риза булсаң, җыйган ашлыкны бергәләп, колхоз исәбеннән тапшырачакбыз.

Хөснулла «компромисс»ка барырга бер дә ашкынып тормый иде булса кирәк, корырак кына әйтеп куйды:

– Уйлашырбыз. Вакыт бар әле, уйлашырбыз, – диде, сүзләренә томанлы вәгъдә салып.

Шакирҗан аны нәкъ менә шул сүзләре өчен якасыннан эләктерергә ниятләде:

– «Уйлашырбыз» дигән сүзне бигрәкләр дә яратасың син, еш кулланасың. Анык җавап юк. Авыл зиратының череп барган коймаларын бергәләп яңартыйк, дидем. Селкенмәдең дә. Ахыр чиктә мин аны тимер рәшәткәләр юнәтеп үзем яңарттым, адәм рәтле кыяфәткә керттем.

Бу сүзләре белән ул Хөснулланың авырткан сөяленә басты булса кирәк, колхоз рәисенең кашлары дугаланып килде.

Әйе, авылдашлары ярдәме белән Шакирҗан авыл зиратын тимер рәшәткәләр белән өр-яңадан уратып алган иде. Үлгәннәрнең рухы шат булсын дигән изге ният белән. Бу эшкә тана, үгез, сыерлар тәрбияләүдән килгән керем акчалары бик тә ярап куйды ул чакта. Халык әнә рәхмәт укый, монысын ишетеп-белеп тора Шакирҗан.

Хөснулланың исә үз туксаны туксан. Ул, йөзен дә сытмыйча, үзенекен аңлатырга тырышты:

– Зират халыкныкы. Халыктан хәл кадәри акча җыярга кирәк булгандыр, бәлки...

(Дәвамы киләсе санда).

«Сөембикә шәҗәрәсе»нә өстәмәләр

Бер-ике ай элек «Казан утлары» журналына шундыйрак эчтәлекле бер язма тапшырган идем. Тарихчы улыбыз Булат, ярты айлык ял-сәфәреннән кайткач, өлешчә тарихка кагылышлы ул хезмәтемнең язмышы белән кызыксынды. Һәм «Нишләп ул язмаңда Розалина апа Шаһиеваның шул ук темага багышланган мәкаләсен искә алмадың? Анда бит ул бик кызыклы фактлар китерә. Аның ул мәкаләсе «Сөембикә» журналы журналистлары Сөембикәгә багышлап чыгарган китапта да бар бит. Ул китапны мин сиңа биргән идем», – диде.

Әйе, бервакыт алар Казансу елгасы буендагы бер музей бинасын «Казан милли мәдәният үзәге» итеп үзгәрткән чорда бергә эшләгән иде шул. Бер зур залда татарларга багышланган тарихи экспонатларны тәртипкә китереп урнаштыруда катнаштылар. Тәҗрибәле сәнгать белгече буларак Розалина алар төркеменең өлкәне иде бугай.

2001 елда «Идел-пресс» басмаханәсендә нәшер ителгән «Сөембикә ханбикә» китабы өстәлемдә. Әлеге мәкаләне язганда аны берничә мәртәбә актарып чыккан идем. Анда кайчандыр Гомәр ага Бәширов тарафыннан язып алынган «Сөембикә бәете» дә, Ризаэддин Фәхретдин хәзрәтнең «Казан ханнары» китабыннан күчерелгән Сөембикә ханбикәгә багышланган бүлекләр дә, Зәки Вәлидинең татар-төркиләр тарихына багышланган китабыннан аерым өзекләр дә китерелә. Кайбер хәзерге заман тарихчылары хезмәтләре дә (мәсәлән, «Сөембикә һәм Сөембикә манарасы» язмасы) бар анда. Ләкин ул китапны актарганда, мин нишләптер Розалина Шаһиеваның «XVI гасыр ядкәре» мәкаләсенә әһәмият бирмәгәнмен икән. Мәкалә башламында бит ярымлык «Сөем-сөем-Сөембикә» шигыре китерелгәнлеге өчендер, бәлки. Ә Сөембикә тормышыннан аның кызына багышланган төп мәгълүмат Розалинаның шул өч битле (137-139) язмасында булган икән.

Шул кыска гына мәкаләдә ул бик тә кирәкле мәгълүмат китерә. «Сүз 1999 елда Милли мәдәният музеена академик А.Н. Каралинның шәхси коллекциясеннән килеп кергән борынгы картина турында бара. Күпләр аны «Сөембикә ханбикә үзенең улы Үтәмешгәрәй белән» дип фаразлый». (Әйе, кулыбыздагы китапның кушымтасында, 281 биттә китерелгән фотосурәт астындагы язмада да шундый хата сүзләр язылган. Димәк, ул китапны туплап чыгаручылар да сәнгатьче Розалина фикеренә әһәмият бирмәгән икән).

● Билгесез рәссам.

«Композициянең уртасында башына асылташлардан, энҗе-мәрҗәннәрдән каелган баш киеме, парча күлмәк, авыр бәрхет камзул, кыйммәтле хәситә кигән чибәр ханым; уңда – ханым алдындагы китаптан күзләрен алмый карап торучы, аның кебек үк киенгән яшь кыз бала; сулда – тәрбияче-дая; артта – асылташлар белән чиккән түбәтәй кигән ир-ат... Сөембикә янындагы алкалы яшүсмернең... Үтәмеш булуы шикле. Бу, һичшиксез, җиде-сигез яшьләрдәге кыз бала! Кызчыкның Сөембикәнең ире Җангали ханнан туган кызы Маһи-Солтан, яки Шаһи-Солтан (1534-1535 еллар) булуы мөмкин. Ул М.Худяков хезмәтләрендә дә телгә алына», дип яза Розалина Шаһиева. Бу абзацны үземнең дә шундый ук фикердә булуымны раслау өчен китердем.

Бу затлы картина-сурәтнең урта гасырларның икенче яртысында, Италиядәге яңарыш чоры остасы тарафыннан эшләнгән булуына да шик юк, дип белдерә мәкалә остасы. «Ул Көнбатыш иле христиан диненә хас дүрт фигурадан гыйбарәт Канонга буйсынган «Изге гаилә» тибында эшләнгән... Рәсем, һичшиксез, шул чор Италия рәссамныкы... Россиядә XVII гасыргача андый сурәтләр ясалмаган. Иконаларга бары «изге Гайсә», «изге Ана» сурәтләрен ясау гына рөхсәт ителгән», – ди мәкалә авторы. Бу тәртипне XVII йөздә иң тәүге бозучылар Идел буе төбәгендә икона мәктәбен оештыручы чукынган татар Строгановлар була, дип яза Розалина. Мин аның шул өлкәдәге оста булуына, бу очракта хак фикер йөртүенә ышанам.

Минем шул ук тарихи эчтәлекле китаплар шкафымда ике томлык «История родов русского дворянства» тупламалары да саклана. Ул томнар тәүге тапкыр 1886 елда Санк-Петербургта, икенче мәртәбәсендә Совет хакимияте тәртипләре үзгәрә башлаган 1991 елда нәшер ителгән. Беренче томның 398-400 нче битләрендә Сөембикәнең атасы Йосыф морза нәселеннән булган, чукынгач «Юсупов кенәзләр» дәрәҗәсендә танылган шәҗәрә вәкилләренә багышланган мәгълүмат урнаштырылган. Йосыф морза 1549 елның җәй урталарында Нугай Урдасы башлыгы – бәк буларак сайлана. Ләкин ул тәхеттә озак утыра алмый. Якын туганы Исмәгыйль морза һәм аның тарафдарлары белән бәхәскә керә, 1554 ел ахырында үтерелә. Ике варисы кала – Ил морза белән Ибраһим морза, дип күрсәтелә әлеге китапта. Шул морза улларының берише тиздән Мәскәүгә барып төпләнәчәк, чукыначак. Зур дәрәҗәләргә ирешүчеләре дә булачак. Безгә якын тарихтан мәгълүм, Николай Икенче патшаның сеңлесенең кызына өйләнгән Феликс Юсупов 1917 елгы вакыйгалардан соң байтак вакыт Франциядә гомер итте. «Истәлекләр язып калдырды», – дигән хәбәрләр дә бар.

Безнең вакыйгага бәйләнеше булу ихтималы чамаланган берничә Юсупов фамилияле кенәз дә бар. Шуларның берсе байтак вакыт Италиядә яшәгән. Затлы сәнгать әсәрләренә табынучы зат булган. Шуларның байтагын сатып алып яисә килешеп, Россиягә дә кайтарган. Сәнгать тарихына багышланган хезмәтләрдә аның исеме еш телгә алына. Ул кайтарган затлы картиналар, скульптуралар бүген дә элекке патша сарайларында яки Эрмитаж музеенда саклана, дигән хәбәрләр дә кабатланып тора. Мәскәү янәшәсендәге атаклы Архангель бистәсе музее да шул ук Юсупов морзалардан калган йорт-утарда урнашкан. Музей экспонатлары – башлыча шул Юсуповлар хәзинәсе ич инде.

Сөембикәгә һәм аның кызына багышланган әлеге затлы картина да шушы Юсуповларның берсе тарафыннан заказ биреп эшләтелмәдеме икән? Әлеге сурәттәге затлы киенгән ир заты да шул Йосыф бәк варисларыннан берсе түгелме икән? Милли мәдәният музеена Сөембикәгә багышланган картина академик А.Н.Каралинның шәхси фондыннан «килеп кергән» дип хәбәр итә Розалина. Ул академик фондының кайчан һәм ничегрәк туплануын да ачыкларга мөмкиндер. Шулай ук Сөембикә ханбикәнең шәҗәрәсен дәвам итүче кызының варислары эзенә төшү мөмкинлеге дә бардыр... Ул кыз да бит затлы гаиләгә – Әстерхан ханлыгы ханы Аккубәк (?-1550) улы Хәйбуллага 1552 елда кияүгә бирелә. Шул хакта Сөембикәгә багышланган тарихи хезмәтендә Һади Атласи да хәбәр итә (493 б.). Шул ук вакыйга Әстерхан ханлыгы тарихына багышланган хезмәтләрдә дә теркәлгән. Ул тарихи язмада Хәйбулланың, атасы үлгәч Мәскәүгә күчеп килүе, «Сөембикә ханбикә кызына өйләнергә телим», – дип, патша Иван Дүртенчегә үтенгәнлеге дә бәян ителә.

Лирон ХӘМИДУЛЛИН,
Г.Тукай исемендәге
дәүләт бүләге иясе.

РЕДАКЦИЯДӘН.

Берничә көн элек язучы Лирон Хәйдәр улы Хәмидуллин 90 яшьлек гомер бәйрәмен каршылады, ә җәмәгате Дания ханым белән бергә гомер итүләренә 55 ел булды. Аларны ихлас күңелдән котлап, сәламәтлек, тыныч тормыш, куанычлы көннәр телибез.

Атнаның сәяси мизгелләре

ҖИРДӘ УРЫН ҖИТӘРЛЕК

Атналык сәяси күзәтүнең бу саны әзерләнгән мизгелдә Бали утравында (Индонезия) «егермелек төркеме»нең (G20) чираттагы саммиты бара. Анда кабул ителгән карарлар һәм эш нәтиҗәләре инде, мөгаен, йомгаклау документларында чагылыш табар. Гомумән алганда, халыкара бәйләнешләрнең әлеге форматы G20 илләренең, актуаль мәсьәләләр буенча үзара очрашып, киңәш-табыш итеп алу урыны буларак кулланыла. Саммит кысаларында ике яклы сөйләшүләр дә үткәрелә. Әйтик, АКШ һәм Кытай лидерлары Джо Байден һәм Си Цзиньпин хәтта 3 сәгатьтән артык та аңлашкан. Яклар уртак тел таба алган кебек. Байден, Кытай белән ике арада яңа салкын сугыш кирәк булмавы, Тайвань мәсьәләсендә АКШның «бер Кытай» мәсләгендә калуы, Си белән бер-берсен яхшы аңлаулары турында әйткән. Си Цзиньпин дә җавапсыз калмаган: ике илнең дә үсеш алуы һәм чәчәк атуы өчен дөньяда урын җитәрлек, дип кистергән. Иң мөһиме – ике лидер да Украинада атом-төш коралын куллану белән янауга һәм аны куллануга каршы булулары турында белдергән. Алар атом-төш сугышы беркайчан да башланмаска тиеш, дип саный. Яклар глобаль проблемаларны алга таба да үзара аңлашып хәл кылырга, ә ике арадагы мөнәсәбәтләрне яңа биеклеккә күтәрергә килешенгән.

Саммитның тәүге көнендә кызыклы чыгышлар байтак булган. Видеоязма режимында анда Украина президенты В.Зеленский да чыгыш ясаган. Илдәге хәлләр буенча ул, бернинди «Минск-3» булмаячак, чөнки Россия аны бик тиз бозачак, Украинага исә «Иминлек турында Киев килешүе» кысаларында иминлекнең ышанычлы гарантияләре кирәк, дип белдергән һәм 10 адымнан торган «тынычлык формуласы»н бәян иткән. Россия исеменнән әлеге саммитта тышкы эшләр министры С.Лавров чыгыш ясаган. Ул Мәскәүнең сөйләшүләрдән баш тартмавы, әмма Киевнең чынга ашмастай шартлар куюы турында белдергән, Зеленскийны Россия белән сөйләшүләр турында Көнбатышның бернинди дә киңәшләрен тыңламауда гаепләгән. С.Лавров Алмания канцлеры һәм Франция лидеры белән сөйләшүләр дә үткәргән. Шул ук көнне ул китеп тә барган. Нәкъ шул вакытта Россия гаскәрләренең Украина калаларын тупланышлы ракета утына тотуы мәгълүм булды.

Башка вакыйгалардан, Херсон каласының Украина контроленә күчүен, БМО Генераль Ассамблеясе Россиянең Украинага репарация түләү механизмы турында резолюция кабул итүен, Бөекбритания премьер-министры Риши Сунакның Россияне «читкә тибәрелгән ил» дип атавын, Россия президенты В.Путинның Мелитополь һәм Мариупольгә «Сугышчан дан каласы» дигән исем бирүен һ.б. билгеләп үтәргә була.

Фоат УРАЗАЙ.

ЯРМӘКӘЙДӘ

● Исламбакты авылы мәчете.

● Мәктәп директоры Зөлфия Гыйләҗева һәм без – сәфәрчеләр.

Тарихчы галим Таһир Кәримовтан әле дөньяга да чыкмаган «Бүләр волосте» атлы китап кульязмасын алып танышуга ике атна да вакыт узмады, без фәкыйрегезгә Оренбург төбәгенә сәфәр кылырга туры килде. Күрше өлкәнең Абдулла районына кергәч тә, юлның сул ягында калган «Исламбакты» дигән күрсәткеч күзгә чалынуга ук, күңел түрендә нindидер кыл чеметкәндәй булды. Оренбургтагы Абдулла белән Башкортстандагы Ярмәкәй районнарының бер-берсенә терәлеп торуын да яттан белми идем. Ләкин руль артындагы сәфәрчегә биш-ун чакрым арага борылып керү олы хафа түгел, шуңа күрә машина тәгәрмәчен Исламбакты дип күрсәткән уң тарафка бордык. Юлы, барча Рәсәй сукмакларына хас булганча, мәдхия укудан шактый ерак тора. Беркадәр күтәртелгән туфрак өстенә ташлы ком җәйгәннәр дә, менә сезгә «шоссе». Дык-дык итеп сикертүләргә күзне йома-йома, Ык елгасын кичтек. Күпернең уң канатында ук берничә йорт утырып калган иде, бераз чакрым ара үткәч кенә, бер-берсенә терәлеп урнашкан урамнар башланды.

«Исламбәхте» дип язылган мәчет капкасын ачып түргә атласак та, Аллаһ йорты безне ябык ишекләре белән каршылады. Хәер, ошбу мәчет эшләми дә, ахры. Ихатасын куе үлән баскан, бер сукмак та юк. Авыл мулласы да мөфтиятнең дәфтәрендә генә исәпләнә бугай...

Мәктәп директоры Зөлфия Гыйләҗеваны телефоннар аша бик тиз таптык. Күршеләрендәге район үзәгенә чыгып киткән икән, ун минут дигәндә, ялт итеп, алга килеп басты. Яшереп тә тормый: «Ярмәкәйгә ерак, безнең авылның байтак халкы Абдуллага йөреп көн күрә, сый-нигъмәтне дә шуннан ташыйбыз», – ди...

Кызыл кирпечтән салынган, ике катлы дәү мәктәп бинасы эченә уздык. Авыл быел үзенең 280 еллыгын билгеләп узган, Башкортстан телевидениесеннән дә махсус бригада килгән, Исламбактыны соңыннан зәңгәр экран аша да мактаганнар икән. Мин фәкыйрегез әлеге авылны Т.Кәримов кульязмасы аша гына укып белэм, шуңа күрә Исламбактының шундый дан алуына хәтта сөенәм дә. Ут күршеләр халык саны алу вакытында нинди генә ярлык чәпәмәсен, әлеге авылны 1742 елда нигезләгән чакта минем якташларым – Актаныш районының берничә авыл вәкилләре ныклап катнашкан бит!..

XVIII-XIX гасырларда Бүләр волосте дип аталган төбәк бүгенге Актаныш, Мөслим, Минзәлә, алардан тыш әле Башкортстандагы Бакалы белән Илеш районнарының берничәшәр авылларын берләштереп торган. Илешнең Исәмәт, Сеңгерән, Кадер, Җәйләү, Торачы, Аккүз, Илеш, Төкәй, Бакалының Киләй авыллары элек Минзәлә өязе составында йөргән дә, 1920 елда «чик сызыгы – Сөн елгасы арьягында» аерылып калган. Ә Бүләр волосте җирләре бик борынгы, андагы Мөшегә түбәсе биләмәләре әле 1523 елда ук Казан ханы Сәхиб-Гәрәй ярлыгы буенча тархан Шәех-Әхмәткә һәм аның туганнарына бүлеп бирелгән. 1552 елда Казан каласын аяк астына егып салса да, Явыз Иван элек Сәхиб-Гәрәй хан тарафыннан бирелгән ярлыкны 1577 елда законлы дип танырга һәм, үз тарафыннан раслап та, Мөшегә түбәсе биләмәләренә сак (оберегательная) грамота бирергә мәҗбүр булган. Бүләр волостеның Мөшегә түбәсенәрәк тупланган Айман, Әтрәкле, Зөбәер, Иркәнәш, Имәнче (Мөшегә авылының тәүге исеме), Исәнсеф, Әмәкәй, Сөякәй, Баек, Сәет, Качкын, Колын, Түке, Усы, Чүплек (хәзер Кызыл Төбәк), Әнәк, Пучы, Чынык, Илтимер, Калтак, Тегермәнлек, Сасыборын (Елгабаш), Чәчер, Чупай, Чат авылларының бик күбесе XVII гасыр дәвамында ук нигезләнгән. Авылларга ясаклы татарларның бер өлеше – Байлар белән Гәрәй волостьларыннан, икенче өлеше – Йәнәй олысындагы Ырыс, Барҗы, Салагыш, Исәнбай авылларыннан күчеп килгән. Мондый күчеш XVIII гасыр дәвамында аеруча нык көчәйгән, чөнки, бердән, татар халкы 1719 елда үткәрелә башлаган тәүге җанисәпне соңыннан көчләп чукындыру өчен кәгазьгә теркәү дип кабул иткән. Икенчедән, 1704-1708 елларда Минзәлә өязе буйлап патшаның кансыз чиновниклары җиткергән 72 төрле яңа салым салуга каршы Күчем Теләкәев белән Алдар Исәкәев җитәкчелегендә, ә 1735-1738 елларда безнең борынгы бабайлардан калган биләмәләрдә һичнинди рөхсәтсез көенчә Оренбург крепостен төзүгә каршы Акай батыр Күчем улы һәм Килмәк абыз Норышев җитәкчелегендә башланган канкойгыч фетнәләр шаулап узган. Минзәлә өязе буенча бишәр мең җайдаклы гаскәр белән Күчем морза яисә аның улы Акай батыр Минзәлә кирмәнен яки бүгенге Гафури районындагы Табын крепостен җимереп юк итәргә дип барган чакта Бүләр волостендагы бер генә авыл ирләре дә сәке астына качып калырга җөрьәт итмәгән, киресенчә, якташ батырлары белән бер сафка басып, җәза гаскәрләре белән куркусыз яуга кергән. Сүз дә юк, карательләр дә татар крестьяннарының берсен дә аяп тормаган. Күчем морзаны махсус юлланган җанкыяр суеп үтерсә, аның яраланып 1737 елда әсирлеккә төшкән улы Акайны Петербург каласына алып китеп, Шлиссельбург крепостенда дар агачына асып үтергәннәр. Баскыннар бу вәхшилек белән генә канәгатьләнмичә, 1736 елда Минзәлә төрмәсе ишек алдында элек Бүләр волосте әйдәманнары булып торган Гомәр Туктаров белән Мәсәгуть Уразаевны да дар агачына аскан. Аннары төрмәгә тупланган 500 әсирне, кырыгар кешелек командалар итеп бер арканга бәйләп, Ык елгасы өстенә алып чыкканнар да, 40 ир арасыннан фәкать берсен генә исән калдырып, 39 ын бәкегә тибеп төшереп юк иткәннәр. Инде җәзалау һәм юк итү давылы тына төшкәч, 1736-1738 елларда Пучы, Зөбәер, Кормаш кебек авыллардан 10-15 әр егетне мәҗбүриләп патша армиясенә гомерлек хезмәткә җибәргәннәр. Аларның сәмруг кошы ике башлы бит ул, хәрбиләрнең нәфесе басылуга чиркәү әһелләре һөҗүмгә күчкән. Шулар Минзәлә өязендәге Мөшегә түбәсеннән генә дә Олы Имән, Уразмәт, Бишкүмәч, Теләнче, Әнәк, Айман, Колын, Кормаш авылларыннан йөзәрләгән егетне эләктереп, мәҗбүри рәвештә чукындырган һәм аларны Нагайбәк крепостена, Чиләбе һәм Оренбург гарнизоннарына солдат итеп озаткан. Әмәкәй, Әтрәкле, Пучы, Чалманарат авылларындагы ирләр кебек тавык тәпиен тагуга каршы килгәннәрне Себер сөргененә һәм каторга эшләренә сөргәннәр.

Әлбәттә, мондый канлы мәхшәр вакытында уяурак һәм тәвәккәлрәк ирләр туган җирләрен калдырып, хәрби гарнизон һәм карательләр гаскәреннән ераграк төбәккә күченеп китү, восстаниеләрдә катнашкан өчен җәзалаулардан котылу ягын караган. Мондый качу-күченүләр әүвәл Казан өязендә кузгала һәм алар Байлар, Бүләр, Гәрәй волостьларындагы авылларга килеп сыену эзли. Аннары инде бүгенге Актаныш яки Мөслим җирлегендәге крестьяннар да ышыграк, тынычрак биләмә эзләп күченә. Әйтик, 1705 елда ук Сөякәй авылыннан Бикмәт Ишмәтов (Бикмөхәммәт Ишмөхәммәтов) җитәкчелегендә 7 гаилә Юрми волостена (бүгенге Азнакай яки Туймазы районы дип күзаллыйк) качып китә. Ә күченгән җирдә барыбер һәрбер крестьянга да ундырышлырак һәм зуррак күләмдәге биләмә кирәк бит. Шуңа күрә Бикмәт белән аның улы Сәет Юрми волостена барып урнашуга ук, Уфа воеводасы исеменә үтенеч хаты юллый. Хатта этиләренең стольник Дмитрий Молоствов командасында Азов каласын төрекләрдән азат итү походында катнашуын искә ала. Үзләренең гомер буе бер дә соңармыйча салым түләп килүләрен дә, Юрми волостендагы ирләрнең аларны «чуаш» дип йөртүен дә искә алалар һәм воеводадан үзләрен һәм биләмәләрен яклау грамоталары бирүен ялваралар.

Өстәвенә, 1742 елда патшабикә Елизавета Петровна фәрманы буенча, Казан өязендәге 536 мәчетнең 418 ен җимереп юкка чыгаралар. Мондый вәхшилеккә түзмичә, Бүләр волостена караучы байтак авыл крестьяннары шул елда ук Башкортстанның хәзерге Ярмәкәй районында урнашкан Кыр-Елан волостена күчеп китә. Ул елда хәзерге Ярмәкәй районы биләмәләрендә

АКТАНЫШЛЫЛАР АВЫЛЫ

● Исламбактыда 19 гасырда ук төзелгән келәтләр.

● Ташландык ындыр табагы.

8-9 гына авыл яшәп яткан, ә бер авылдагы халык саны 40-60 тан да артып китмәгән була. Бүләр волостеның Төкәй, Сөякәй, Кормаш, Әмәкәй, Бикчәнтәй, Исәнсеф, Усы, Качкын, Илтимер авылларыннан киткәннәр Ык елгасының ике як яры буйлап тарала. Бикчәнтәй авылыннан күчкән Бикчәнтәй Туймәтов, Әбдесәлим Йөртүкәев, Габделкәрим һәм Якуп Уразаевлар, Биккенә Усеев (Хөсәенов-?), Әбди Калмачев, Тимер Юлдашев моңа кадәр Бүләр биләмәсенә Байлар волостеннан килеп утырган типтәрләр санала. Кормаш авылыннан Искәндәр Кормашев һәм Давыт Сөләйманов, Әмәкәйдән Уразмәт Тукышев, Исәнсеф авылыннан Сәет Мәскәү улы белән Йосыф Сөләйманов; Качкын авылыннан Иткенә, Сәет һәм Хәсән Морзакаевлар, Үтәй Сөләйманов, Сөякәйдән Кадермәт Ишәлин, Котлымәт (Котлымөхәммәт) Мәскәү улы, Сөлек Сәфәров башкорт катламына язылган татарлар була. Алар белән бергә Кормаш авылыннан Мөслим Бигәшев, Мостафа Таймәтев, Илтимердән Йосыф Иткинин, Зәет Илмурзин, Әбки Уркин кебек татар типтәрләре булып саналучы крестьяннар да күчә. Күчмәннәр исемлегеннән күренгәнчә, Искәндәр Кормашев – ул Актаныш районындагы Кормаш авылын нигезләүче әйдәманның улы, ә Бикчәнтәй Туймәтов – Бикчәнтәй авылын нигезләп китүче шәхес була. Димәк, күчмәннәр арасында яңа тормыш кора алырдай тәҗрибәле әйдәманнар җитәрлек, шуңа күрә Ярмәкәй районында да алар үз эзен калдыра...

Исламбакты авылына Мөшегә түбәсенең Әтрәкле авылыннан Исламбакты Атнагол улы җитәкчелегендә килгән татарлар нигез сала. Атнаголның өч улы өч төбәккә тарала. Аның беренче улы Уразман – Ырыссу-Тамак, икенчесе Уразбакты – Абдулла (хәзер Оренбург өлкәсендәге район үзәге), өченчесе Исламбакты менә шушы, Ык буена барып урнаша. Исламбакты үз исемендәге авылны нигезли. Аннары аның өч улы – Солтангол, Исламгол һәм Моратхуҗа да үз йортларын салып, башка чыга. 1795 елда 5 нче ревизияне үткәргән чагында Атнаголның туган авылы Әтрәкледә 216 «башкорт» һәм 17 типтәр яшәсә, яңарак кына калыккан Исламбактыда нибары 35 «башкорт» белән 57 типтәр генә яши.

Әмма 1800 елда ук Исламбактыга янә 6 татар һәм 3 «башкорт» гаиләсе килеп өстәлә. 1816 елда бирегә Исламбактының күршедәге Абдулла авылында яшәгән абыйсы Уразбактының улы Муллагали күчеп утыра. Ул – 1812 елгы Ватан сугышында һәм Парижны яулап алуда катнашкан, нindидер офицерны үлемнән коткару хакына батырлык кылган, шуның өчен офицер һәм дворян дәрәҗәсенә лаек булган туган. Ул йорт (берничә авыл) старшинасы да булып алгач, әлбәттә, исламбактылылар уңышы тауга менә башлый. Беркадәр сикертеп әйтсәк, 1913 елда Исламбактыда яшәгән халыкның саны 1379 кеше исәпләнә. Дөрес, Беренче бөтендөнья сугышына чыгып киткән 34 авылдашның байтагы немецларга каршы корылган траншеяларда агулы газ һөҗүменнән һәлак була. Аннары авыл халкы һәм ирләре Гражданнар сугышында, 1921 елгы ачлык елларында кырыла, 1930 елларда кулакка чыгарылып Себер котыпларына сөрелә. Читкә сөрелгән Гаффар, Әхмәтзакир, Фатыйх муллаларның йортларын сүтеп, 1937 елда Исламбактыда җидееллык мәктәп бинасы күтәрәләр.

Бөек Ватан сугышына авыл 260 ка якын ирен озата, аларның 150 се туган якларына әйләнеп кайта алмый. Исламбактылылар арасында Ленин орденнарына лаек булган каһарманнар да, татар генералы Миңлегали Шәймөратов дивизиясендә полковник дәрәҗәсенә ирешкән Ибраһим Фәттахов, шул ук дивизия җайдаклары арасында чаялыгы белән аерылып торган Әхмәтзакир Вафин да булган. «Башкорт дивизиясе» дип аталгач, Уфа мөтәгалимнәре андагы җайдакларның барчасын да «ысын башкортныкы» дип күкрәк суга. «Сукыр тавык өчен бары да бодай», дигән төсле такылдаучылар Бүләр волостеның Мөшегә түбәсе татарларын да «Мөшегә ыруы башкортлары», дип тәкрарлый бит һаман...

1917 елда Исламбактыда 235 йорт исәпләнгән. Биредә тамыр җәюгә үк «асаба башкорт» итеп тойган татарлар Мөшегә түбәсендә яшәгән чакта үзләрен Сәхиб-Гәрәй хан ярлыгы белән тархан дәрәҗәсе алган Шәех-Әхмәт оныклары дип санауны һәм, билгеле ки, имана җирен дә мулрак күләмдә бирүне таләп итә башлый. Бер дә нигезсез генә булмагандыр, 1956 елда галим Г.В.Йосыпов Исламбакты авылында 1807 елда төзелгән һәм тархан Шәех-Әхмәткә килеп ялганган нәсел шәҗәрәсен таба (Мухамедьяров Ш.Ф. Тарханный ярлык казанского хана Сахиб-Гирея 1523 г. // Новое о прошлом нашей страны. М., 1967. С. 104-109).

Югарыда искә алганча, Исламбакты авылы үзенең 280 еллык юбилеен бәйрәм иткән. Укучылар мәктәптә авылны нигезләүчеләр турында истәлекләр туплаган, ә З.Әгълетдинов атлы җирле тарихчы Исламбакты авылындагы байтак гаиләнең шәҗәрәләрен аерым китап рәвешендә нәшер иткән. Кабат исбатлап тору һич кирәкмәс. Китапта авылга нигез салучы Исламбакты Атнагол улының да, күчеп килгән ясаклы татарларның шәҗәрәләре дә бар. Шунысы гына кызганыч – 1742 елда Бикчәнтәй, Кормаш, Илтимер авылларыннан күчеп килгән тәүге гаилә дәвамчыларының бик күбесе җанисәпләр вакытында «башкорт» булып языла. Ә югыйсә, Октябрь инкыйлабына чаклы да, хәтта 15-20 ел элек тә аларга сыңар гына сәгать тә башкорт теле кермәгән, Исламбактыда туганнарның һәркайсы туган теле дип татар телен таныган. Йорттан-йортка йөреп сөйләшсәң дә, «җирле» халык арасыннан бер генә гаилә дә башкортча сәлам бирә белми. Иң яманы: исламбактылылар озакламый татар теле белән дә саубуллашыр сыман. Егермедән артык гаилә үзләренә Абдулла авылындагы ятимнәр йортыннан берешәр, икешәр баланы тәрбиягә алган. Элек авылда гөрләгән колхоздан җилләр искәч, хәзер чит балалар тәрбияләп күңел юаталар. Ни кызганыч, Исламбактыны бүген гөрләп яши торган авыл, дип булмый шул. Вертикаль йөгән һәм тәртәләр арасына куып керткәч, авыллар да сүнә.

Вахит ИМАМОВ.
Автор фотолары.

Малик (1180)
Кыйпы (1225)
Ильман (1270)
Уразман (1315)
Норош (1360)
Мокамат (1405)
Махмут (1450)
Муса (1495)
Нуркай (1540)
Юкасун (1590)
Бикуш (1638)
Атнагол (1686)

Исламбакый (Исламбакты) (1715)
Уразбакты (1724)
Уразман (1748)

● **Исламбакты Атнагуловның нәсел шәҗәрәсе. Ул 1913 елда «Шура» журналында да басылган.**



Список землепользователей	Кол-во душ	Примечание
Исламгул Исламбактин	13	
Габдрахман Исламгулович	5	
Давлеткул Султангулович	5	
Давлетшa Султангулович	13	
Моратхужа Исламбакиевич	5	
Забир Тукаев	5	
Бактагир Тукаев	4	
Губатулла Баширов	2	
Абдулгани Аднагулов	2	
Муллагали Уразбактин	1	жили
Абдулвалий Муллагалиевич	3	в Сулли-Сат
Шакмурза Бикмурзович	1	-"-
Хамит Уразманин	5	-"-
Хисматулла Бакиров	2	-"-
Припущенники		
Амир Султанмуратович	2	жили
Гильман Аширов	3	в Сулли-Сат
Зайсан Мукинов (Мукановы)	2	-"-
Гиниятулла	1	-"-

● **1816 елда Исламбактыда үткәрелгән ревизия мәгълүматлары.**


● **Мондый тамгаларны үзләрен Казан ханы Сәхиб-Гәрәй ярлыгындагы тарханнар нәселеннән дип санаган Исламбакты авылы (Кыр-Елан волосте) вотчинникларында да күрергә мөмкин.**

ФОТОГРАФЛАР РӘИСЕ

Рамил Якуб улы Галиев 1985 елдан алып республика һәм илкүләм мәгълүмат чараларында эшли. 2000 елдан башлап Мәскәү каласындагы «Коммерсантъ», «Труд», «Комсомольская правда» газеталарында хезмәт куя, АКШның «Tourist» журналында да, РФ Президенты В.Путинның журналистлар пулында да эшләргә өлгерә. Ул – Татарстанның матбугат һәм гаммәви элемтә чаралары атказанган хезмәткәре. 2016 елдан башлап «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында фотохәбәрче вазыйфаларын башкара.

– Рамил, үткәнгә әйләнеп карасаң, кайсы матбугат чарасында осталыгың аеруча чарланды дип уйлыйсың?

– «Коммерсантъ»та эшләгәндә, зур һөнәри мәктәп үттем, осталыгым күбрәк шунда чарланды. Башкалада газета-журналлар берничә йөз бит һәм аларның һәркайсысы иң алдынгы булырга омтыла.

– Хәзер Татарстан фотографлары берлеген дә җитәкләсең, бу вазыйфа синең өчен ят нәрсә түгелме?

– Мин бит фотожурналистика өлкәсендә 1985 елдан бирле. Мәдәни чараларны оештыру эшләрен дә төптән беләм. Быел, ноябрь аенда шушы берлеккә җитәкли башлаганыма ике ел тулачак.

Июль аенда Н.Назарбаев урамындагы 35 нче йортта, 1936 елда ук төзелгән һәм «Соры йорт» дип йөртелгән бинада ТР фотографлары берлегенең «Сфера» фотогалереясын ачтык! Монда кайчандыр балалар бакчасы һәм кечке мәктәп урнашкан булган. Ул галереябыз зур, ике фотокүргәзмә һәм инсталляцияләр залыннан гыйбарәт. Моннан кала бирегә фотостудия дә ачтык.

«Сфера»да Фотография музеебыз да бар. Аны тулыландыра барачакбыз, әйтик, бер көнне фотограф Р.Якупов ике китап бүләк итте. Музеебыз уникаль фотоаппрататуралар белән дә баетылачак. Моннан кала ТР Журналистлары берлеге музеендагы бер стенд тулысынча фоторепортерларга багышланган. Ләкин үз максатыбыз буенча без барлык иҗаттарларыбызның хезмәтләре җыйналган аерым музей булдырырга, фотографларны унъеллыклар буенча квалификацияләп чыгарга, Татарстан фотографиясе өлкәсен тулысынча барларга телибез. Бу – зур хезмәт һәм аны башлап җибәрергә кирәк иде.

Берлектә барлыгы ике йөз кеше исәпләнә, аларның унбише – үтә дә актив. Без җәй көне «Урам чаты» дип аталган тәүге гомуми күргәзмәбезне дә ачтык. Икенче күргәзмәбез ике яшь фотографыбыз иҗатын яктыртты. Мин яшь буын иҗатчыларыбызга бик игътибарлы. Дөрес, алар узган гасырда Татарстанда хезмәт куйган, инде бакыйлыкка күчкән фотографларыбызны белми дә... Аларның А.Биктимеров, М.Шакиржанов, В.Мартенков, Н.Курамшин, Р.Ярулин, Н.Седов иҗаты хакында гомумән ишеткәне юк.

Әйе, безнең татар әдипләре, композиторларыбыз күптән барланган, аларның биографияләре, язган әсәрләре хакында да интернет сәхифәләрендә укып була, ә менә татар фотографларының гына әлегәчә квалификацияләнгәне юк. Татарстан фотографиясе тарихы үсешенә күп хезмәт керткән фотографларыбыз буенча әзлекле тарихи нигез, мәгълүмати база әлегәчә булдырылмаган. Алар хакында берничә томнан торган җитди биографик язмалар да тупланмаган. Әйткәнемчә, безгә кадәр кемнәрнең бу өлкәне алга этәргәнен күпләр гомумән дә күзалламый. Бу киләчәк буын өчен дә кызык булачак. Аналогия, цифрлаштыру өчен дә мондый китаплар булдырылырга тиеш, алар буенча без Татарстаныбызның чын тарихын да күзаллый алачакбыз. Бу – бик мөһим бурыч!

Хөкүмәтебездән дә ТР фотографлар берлегенә булышлык күрдек, тиздән безнең сигез ветераныбыз республика ял йортында булып, үз сәламәтлекләрен ныгытачак, монысы өчен дә рәхмәт. Әлбәттә, без – яшь берлек, алдыбызда торган мәсьәләләр шактый. Шуңа күрә Татарстан илбашы Р.Миңнеханов белән нибары биш минутка гына булса да күрешеп, аңа татар фотожурналистикасы мәсьәләрен ачыклап бирәсем килә.

– Рамил, быел үз иҗат җимешләрең нигезендә күргәзмәләр уздыра алдыңмы?

– Август-сентябрьдә Россия этнография музееның Мәрмәр залында Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгына багышланган «Безне туры юлга күндер» фотопроекты, күргәзмә уңыш белән үтте. Күргәзмәнең идеясе – минеке, ә менә аны тормышка ашырырга Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм «Татмедиа» булышлык итте. Күргәзмәдә 1989 елда төшергән бихисап тарихи фотоларым экспозицияләнде. Аларда 1989 елда узган «Идел буе җыены» күренешләре. 1989 елны да Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгы билгеләнеп үткән иде. Ул мөселман календаре хисабы белән саналды, ә 2022 елда бу дата григориан календаре буенча бәйрәм ителде. 1989 елда шушы бәйрәм уңаеннан оештырылган сәфәрдә мин дә катнаштым. Бу күләмле бәйрәм чарасында кырык чит ил делегациясе дә булды. Ул чактагы автобус маршрутыбыз Казан –Уфа – Чаллы – Алабуга калалары аша узды, соңрак Болгарга да барып җиттек. Тулы фоторепортаж хәзерләдем. Шул чара барышында җыелган архивым аша кешеләр күңелендә фотосурәтләргә кызыксыну уятырга теләдем һәм менә Питер татарлары әлеге күргәзмәне ошатып карады. Ул фотолар – юкка чыга язган хезмәтем, 2006 елда Мәскәүнең «Пресса» нәшриятында янгын чыкты, ә минем архивым шунда саклана иде. Негативларыма зыян килде, ләкин алар бөтенләй янып бетмәде, янгын сүндерү күбегенә эләкте. Ул плёнкаларны озаклап юып, фотоларны саклап калырга дусларым да булышты, шуңа күрә бу сурәтләр – утны да, суны да кичкән сурәтләр!

2023 елда иске Казаныбызга багышланган яңа күргәзмәмне ачачакмын. 2015 елда Мәскәүдән Казанга кайткач, башкалабызның яхшы якка үзгәрүенә игътибар иткән идем. Шәһәр күренешләрен күпләп фотога төшердем. Әлеге күргәзмәгә шулай ук бүгенге яшь буын күзаллый да алмаган иске Казан күренешләрен дә элеп куячакмын.

Мин гел шул хакта искәртә киләм: әдәбият – ул бер нәрсә, анда чорны һәркем үзенчә интерпретацияли. Ә фотолар – үтә дә объектив документ. Шунысы да бар, безгә тарихи хроникалы булырга җитешергә кирәк. Мин, мәсәлән, үз милләтемне, аның гади хезмәттәге кешеләрен дә, талантлары белән планета күләмендә шөһрәт казанган сәләтлеләребезне дә бик яратам. Аларның һәрберсенең сурәте фототарихыбызда калырга тиеш. Әйтик, 1992 елда Казанга даһи биюче Р.Нуриев килгән иде. Аны бирегә башка илләрдәге кебек йөздән артык фотограф каршы алмады бит. Нибары өч-дүрт фотограф кына төшерде. Мин данлыклы татар биючесенең бүлмәсенә кергәч, Рудольф Нуриев торып басты һәм яныма ук килеп, кул биреп күреште. Минемчә, ул үз Ватанын өзелеп сагынып кайткан иде, шул көн-

нәренең фотосурәтләрдә калуын да бик теләде. Аны фотога төшерү өчен театрга һәм филармониягә нибары өч фотограф килер дип кем уйлар, ләкин бу нәкъ шулай килеп чыкты... Әйе, барысына да җитешергә кирәк. Гомерем буе, шушы максаттан чыгып, милли тарихыбызны төшерәм...

– Бүгенге матбугат чараларында фотолар әһәмияте сизелерлек артты...

– Хәзерге матбугатны моңа кадәргесе белән чагыштырып карасак, фото һәм текст бер тигез микъдарда диярлек. Безгә мәгълүмати сугышта җиңелеп калырга ярамый. Без татар тарихын өзлексез яктыртып торырга тиеш. Аннары кайбер фотосурәтләр йогынтысы хакында да әйтми булмый. Хәзерге заманча технологияләр бер фотога гына да илледән алып биш йөзгә кадәр өстәмә информацион катлам сала ала. Бу хакта да онытмаска кирәк.

Фотосәнгать тарихы, аның кануннары хакында университет студентларына, яшь фотографларга лекцияләр үткәрәм. Татарстанда балалар өчен фото сөючеләр түгәрәкләре җитәрлек күләмдә, әмма ни кызганыч, республикабызда әлегә кадәр бер балалар фотомәктәбе дә юк.

Журнал тышларыбыз да иң матурлардан булырга тиеш, чөнки күп кенә кала-сала туристлары безнең матбугат чараларын да үзләре белән истәлеккә алып китә. Татарлар – иң чибәр халыкларның берсе. Без моны фотоларыбыз аша да ассызыклый алабыз.

– Синеңчә, безгә кемнән үрнәк алырга?

– Без чуаш фотохәбәрчеләреннән бераз калышабыз дип саныйм. Минә шушы көннәрдә Чуашстан фотографлары белән очрашып сөйләштем. Әлар үз республикалары фотографлары хакында саллы китап та бастырып чыгарган икән инде. Мондый төр китап бездә дә нәшер ителергә тиеш бит. Ләкин моны башкарып чыгар өчен ярдәм кирәк. Чуашстанда үз фотографлары иҗатына багышланган музей да ачылган...

– Тук илләрдә фотографияләргә чүп итеп карамыйлар. Уңышлы фотоларны зур суммаларга сатып та була. Бездә фотобазар кайчан башланып китәр?

– Минемчә, хәзерге үтә байлар катламы инде картиналар гына тупламый. Яхшы фотосурәтләрне сатып алу, фототупланмалар җыю белән мавыгу бүгенге байлар арасында тарала бара. Ләкин аларның игътибарын җәлеп итү өчен эксклюзив темаларга алынып, үз йөзеңне булдырырга, даими үсеш өчен зур күргәзмәләрдә катнашырга, социаль челтәрләрдә дә үтә активлашырга кирәк. Югары дәрәҗәдәге фотолар аларның авторын таныта барырга тиеш. Яхшы фотосурәтләр тарихи кыйммәткә ия, еллар узу белән, аларның бәяләре арта гына барачак.

Татарстандагы фотографларның иң еш ишеткән сүзләре: «Бу фотоларны бүләк итеп бир әле!» Кешеләр фотографларның хезмәте аларга ни өчендер бушлай гына, бүләк ителеп бирелергә тиеш дип фикерлиләр, ә бит иҗатчы кыйммәтле аппарат та алган, фотога төшерү өчен хәйран күп вакытын да сарыф иткән була... Фотобазар булдыру үзебездән дә тора. Минә архивыбызда сакланган яки башкалар китергән фотоларга бәя кую өчен экспертлар комиссиясе төзергә булдык. Тиздән бу комиссия, фотоларга һөнәри караштан үз бәяләмәләрен билгеләр.

Әмнә борынгы, тарихи фотоларның бәясенә килгәндә, алар кыйммәт, чөнки «юеш процесс» чоры узып китте һәм мондый фотолар инде елдан-ел сирәгәя, аларның бәяләре дә арта. Аларның Татарстанда ничә сум торуларын әйтү – авыр мәсьәлә... Уйлавымча, тарихи фотоларның бәясе бүгенге көндә өч меңнән башлана.

Аннары диварларга элеп куелган фотолар алар бит әле кечкенә балалар өчен дә бер тәрбияви чара. Фотолар, төрле картиналар, яхшы көйләр белән бер рәттә булып, милләтнең мәдәни кодын тәшкил итә, алар үз балаларына милли тәрбия бирүче гаиләләр мохиты өчен бик тә кирәк. Мин үзем дә фотографияне үлеп яраткан гаиләдә үстем.

– Әсинең гаиләдә сакланган иң борынгы фотолар ничәнче елда төшерелгән? Архивларында борынгы гасыр фотолары булганнар аларны бүген нинди сәхифә аша башкаларга тәкъдим итә ала?

– Әнием бай Бикчәнтәевләр нәселеннән иде. Ул нәселдән муллалар да, иҗат кешеләре дә чыккан... 1905 елдан башлап төшерелгән фотолар саклангандыр дип уйлыйм, һәрхәлдә безнең гаиләдә XIX гасыр фотолары да булган.

Гаиләләрендә борынгы фотолар булганнар аларны «ВК»дагы, 7,5 меңнән артык укучы теркәлгән «Старинные татарские фотографии / Иске сурәтләр» сәхифәсенә урнаштыра ала.

– Рамил, Татарстанда һәйкәлләр хәттин ашкан. Әфотохәбәрчеләргә багышлап һәйкәл куярга кирәк дип саныйсыңмы?

– Әйе. Безнең милләтебездән дә Бөек Ватан сугышында хәбәрчеләр дә, фотографлар да катнашкан. Аларны искә алып, шул һәйкәлгә чәчәкләр салыр идек... Ә мондый һәйкәл әлегәчә юк. Моннан тыш та татарлар арасында нинди генә каһарманнар, акыллы, талантлы затлар юк! Аларның да күбесенә һәйкәлләр, бюстлар урнаштырылмаган. Мәсәлән, халыкара гроссмейстер, быел матур гомер бәйрәмен билгеләп үткән Алисә Галләмовага бюст куелмаслыкмы?!

Безнең, әйтергә кирәк, символларга да исебез китә. Мәсәлән, шул ук төрки символ – лалә чәчәге сурәтенә. Ул Татарстанда да киң таралган. Әмма игътибар итсәк, аның күләмле ясалышы беркайда да юк. Шуңа күрә мин Ирек мәйданы скверына күләмле, фонтан белән бәйле, җырлый торган «Лалә чәчәге» урнаштыруларын үтенеп, хөкүмәт җитәкчелегенә мөрәҗәгать тә иткән идем. Өстәвенә, әлеге территориядә консерваториябезнең Зур Концертлар залы да, укыту бинасы да, опера һәм балет академия театрыбыз да янәшәдә урнашкан бит. Бу җырлап торучы «Лалә» туристлар өчен дә кызыклы арт-объект булыр иде. Ләкин мине янә ишетмәделәр...

– «Сфера»га әйләнеп кайтыйк әле, фотогалереяда бу айларда нинди күргәзмә ачырга ният кылдыгыз?

– Экологиягә багышланган «Мәдәни адым. Үзеңнән башла» дип аталган күргәзмә ачабыз, аны Татарстан Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы белән бергәләп әзерлибез. Ул мохитны чүп-чар белән пычратуга каршы көрәшне чагылдырачак. Бу – зур мәсьәләне яктыртучы заманча инсталляцияләр дә куелган күргәзмә булачак. Галимнәр тамашачыларга чүп-чар эшкәртүче замана җайланмаларын да күрсәтәчәк.

– Син үзеңнең беренче фотокитабыңны да нәшер итәргә өметләнә идең...

– Өметләр тормышка ашты. «Казань из кофра» дип аталган фотокитабым, Казандагы нәшрият тарафыннан әзерләнеп, Белград каласында басылып чыкты.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Хатлар яздым утырып

ХӘТЕРСЕЗ ХӘТЕР КӨНЕ

30 елдан артык вакыт барышында, һәр ел саен митинглар оештырып үткәрелә торган Хәтер көне быел рәсми рәвештә билгеләп үткәрмичә генә узып китте. Казан шәһәре җитәкчелеге төрле сәбәпләр табып, Хәтер көнен билгеләп үтәргә рөхсәт бирмәүләренә карамастан, милли җанлы милләттәшләребез Сөембикә манарасы янында җыелып, Казанны яулап алганда һәлак булган милләттәшләребез рухына дога кылды. Милли җанлы шагыйрьләребез Хәтер көненә багышлап язылган шигырьләрен укыды. Тәртип саклаучылар дип әйтикме аларны, алар да бер кырыйда басып торып, фотога төшереп тордылар. Тавыш-гауга, кулга алулар булмыйча узып китте үзе бу көн.

Аннан Кол Шәриф мәчетенә кереп, өйлә намазын укуда катнаштык. Хәзрәтләр намаз укыганда, Казанны яулап алганда һәлак булучыларны искә алып, алар рухына багышлап дога кылырлар дип өметләнеп утырубыз акланмады. Үз дәүләтчелегебезне саклап калуда барган бәрелешләрдә һәлак булучылар рухына багышлап, Казанда һәйкәл кую турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 нче елда чыгарылган карары хәзергә кадәр үтәлмәгән һәм кайчан үтәләчәге дә билгеле түгел. Бу һәйкәл мәсьәләсе бик четерекле булып чыкты. 30 елдан бирле, бу турыда бертуктаусыз язып, сөйләп торулар буш сүз булып калды. Үз иленең азатлыгы өчен көрәшүчеләр җинаятьчеләр булып саналмыйдыр бит, киресенчә, андый кешеләргә багышлап куелган һәйкәлләрнең дөнья буйлап таралган икәнен күреп торабыз югыйсә. Каланы яулап алганда һәлак булганнар хөрмәтенә куелган һәйкәлнең Казан уртасында торганын күрәбез. Үз ватанын саклаганда һәлак булучыга караганда яулап алучылар хөрмәтлерәк санала микәнни?

Шул ук хәтер көнендә, ТНВ каналындагы яңалыклар тапшыруында Хәтер көненә багышланган сүз әйтүче булмасмы дип карап утырсам да, бу турыда ләммим. Анда хәрби бәрелешләрдә катнашучыларга кием-салым, акча җыюлар, полигоннарда ату осталыгына өйрәтүне күрсәтәләр иде. 74 яшьлек хәрби ветеранның балаларга каратэ алымнары кулланышы турында дәрес үткәрүен дә күреп тордык. Сарман районында яшәүче бер ирнең малаен ничек итеп сугыш алымнарына өйрәтүен күрсәттеләр. Ә шундый әһәмиятле тарихи көнне күрмәмешкә салыштылар.

Рәфкать ИБРАҺИМОВ.
Казан шәһәре.

Күренекле

Академик Рүзәл Юсуповның, ике телдә язылган “Милләтебезнең иминлеге сагында. За развитие нации” дигән китабы дөнья күрде. Анда бу зур галим һәм җәмәгать эшлеклесенең вакыйгаларга бай тормышы, нәтиҗәле гыйльми-педагогик, иҗтимагый эшләре мавыктыргыч итеп сурәтләнгән, бүгенге чынбарлыкка карата кыю фикерләре бәян ителгән. Шулай ук аның турында хатирәләр, хезмәтләренә бәяләмәләр, күп санлы китап һәм мәкаләләренең исемлеге урнаштырылган (“Сүз” нәшрияты, Казан, 2022 ел, 560 бит).

Авторның балачагы һәм үсмер еллары, Казанда техникумда укыган чоры, аннары Курган өлкәсендә эшләгән һәм армиядә хезмәт иткән дәвере укучыны тәэсирләндерерлек итеп язылган. Ул вакытларны башкача тасвирлау мөмкин дә түгелдер. Сугыш еллары, аннан соңгы чор Советлар иле халкы өчен искиткеч авыр, чыдамлылык, рух ныклыгын сынау заманы булды. Ул заман кешеләренең берсенең генә дә кичерешләрен битараф кына тыңлап булмыйдыр.

1941 нче елның җәе. Фашистлар Германиясе Советлар Союзына каршы дәһшәтле сугыш башлый. Миллионнарча ирләр кебек, Әтнә районындагы Кышкар авылының Йосыф Абдуллаҗаны да сугышка китә. Өйдә хатыны Лотфикамал дүрт улы белән торып кала. Иң олысы Равилгә 10 яшь тирәсе, иң кечесе Әнәскә бер яшь тә тулмаган. Җиденче яше белән барган Наилдән кечерәге Рүзәлгә өч яшь тә юк. Булачак галим Рүзәлнең бала чагы һәм яшүсмер чоры ачлык-ялангачлык, фәкыйрьлек һәм авыр крестьян хезмәте белән үтә. Әнәс энесе белән кышын, бер капчык ашлык салган чана тартып, 30 чакрымлы Арча станциясенә киткән әниләрен, мичкә ягу өчен, басудагы эскертләрдән салам алып кайту, су буеннан тал чыбыгы җыю белән мәшгуль абыйларын салкын өйдә ач килеш көннәр буенча көтеп утыруларын, дүрт-биш яшеннән күп төрле өй эшләрен башкаруларын, ә үсә төшкәч, җәйге каникул вакытында, шактый авыр колхоз эшләрендә катнашуларын һәм башка җәфалы тормыш эпизодларын тыныч кына уку мөмкин түгел. Шулай да Рүзәл Юсупов авыр балачагын офтанып, каргап сөйләми: ул чакта беркемнең дә тормышы җиңел булмаганлыгын аңлый.

Рүзәлгә кечкенәдән үк китап җене кагылган була. Укырга ярату сыйфаты, гомере буенча сакланып, аның күренекле галим булуына китереп җиткерә. Рүзәлнең мәктәптә укый башлавы да үзенчәлекле була. Ул, укырга, язарга, санарга абыйлары ярдәме белән өйрәнә, җидееллык Кышкар мәктәбен гел бишлегә генә тәмамлап, Казан кооперация техникумына укырга керә.

Уку срогы өч кенә ел булганлыктан, шушы вакытта гына урта мәктәп программасын узу, махсус белгечлекне үзләштерү, ике тапкыр практика узу кемгәдер булмаслык эш тоеладыр. Әмма бу мөмкин булган. Һәр көнне сигезәр сәгать укыйлар, шуның өстенә, татар мәктәбен тәмамлап килгән Рүзәл белән дүрт укучыга рус теленнән өстәмә дәресләр бирәләр. Яшәү шартлары да кырыс: техникумның тулай торагы булмый, кеше фатирларында торалар, ашау такы-токы гына, стипендияне бер айга җиткерергә кирәк, авылдан, өйдән ярдәм юк: үзләре дә очны очка көчкә генә ялгап баралар. Стипендияне исә дүртлегә-бишлегә укысаң гына бирәләр.

Түзә Рүзәл. Табигатьтән бирелгән чыдамлык ярдәм итә. Техникумны уңышлы тәмамлап, унҗиде яше дә тулмаган кооператор егет юллама белән Курган өлкәсенә эшкә җибәрелә. Анда аны чираттагы кырыс сынаулар көтә. Ярый әле анда озак эшләргә туры килми. Тиздән Рүзәлнең армиягә алынып вакыты җитә. Кышкар егете Памир тауларында, атка атланып, Әфган чиген саклый.

Армиядә Рүзәл В.И.Ульянов-Ленин укыган Казан университетына укырга керергә дип, хәл итеп куйган була. Ул татар мәктәбенең 8-10 классларында укымаган килеш, университетта татар филологиясе буенча белем алырга дигән карарга килә.

Рүзәл Юсупов студентлык тормышының беренче көннәреннән үк белем алуга, җитди мәгърифәт иясе булу өчен әзерлек эшенә бөтен куәтен, дәртен салып керешә. Аны беренче курстан ук үзе бер институт күләмендәге дүрт бүлектән торган зур тарих-фиология факультетының комсомол секретаре урынбасары, ә икенче курстан – секретаре итеп сайлап куялар. Ул Казан читендәге өйләренә, гадәттә, соң гына кайта, ял көннәрен дә университетның уку залында яки республика китапханәсендә үткәрә.

Рүзәл, факультет күләмендәге зур иҗтимагый вазыйфасыннан тыш, үз группасы тормышындагы эшләрдән дә читтә калмый. Бу группа исә үзенә бертөрле, гаҗәеп актив була. Рүзәлләр группасы җәйләрен, көзләрен колхоз-совхозларда төрле эшләр башкара. Эштән соң авылларда кичләрен концертлар куя. Ленар Җамалетдинов (соңыннан гыйльми хезмәткәр, Тукай премиясе лауреаты) концертларны алып бара, интермедияләр күрсәтә, Лениза Галиева (киләчәктә атказанган укытучы) җырлый, бии, Равил Фәйзуллин (хәзерге халык шагыйре, Тукай премиясе лауреаты), Шамил Маннапов (шагыйрь, журналист), Әнвәр Шәрипов (профессор, шагыйрь), Фарсель Зыятдинов (күренекле бакчачы, икътисад галиме, язучы) үзләренең шигырьләрен укый, Рүзәл Юсупов – гармунчы, биюче – концерт алдыннан халыкара темага лекция укый, группа хор белән җырлый. Группадашлары – булачак күренекле галимә Фирдәвес Гарипова, һәм Тел, әдәбият, тарих институты директоры урынбасары Шәрифҗан Асылгәрәев тә алар белән бергә. Мондый чараларны комсорг Роза Гатиятова-Ханнанова (соңыннан республиканың китап палатасы директоры) оештырып йөри. Менә шундый ялкынлы йөрәкле егетләр-кызлар коллективында уза Рүзәлнең студентлык еллары.

Университеттан соң Рүзәл радиода тәрҗемәче булып эшли. Аңа тиздән телевидение редакторы вазыйфасын тәкъдим итәләр. Ул Казан телевидениесенең пропаганда бүлеге редакторы булып китә: аның тормышында бәрәкәтле яңа этап башлана.

Телевидение журналисты эше кызык та, җаваплы һәм мәгънәле дә. Пропаганда редакциясе хезмәткәрләренә, идеология өлкәсенә караган тапшырулар әзерләү белән бәйле булганлыктан, таләпләр югарырак. Казан телевидениесендә алтмышынчы елларда җитди карашлы, әзерлекле редакторлар, режиссерлар, Туфан Миңнуллин кебек күренекле шәхесләр

галим китабы

эшли. Җитәкчеләре дә – бай тормыш юлы узган, тәҗрибәле, эшлекле кешеләр. Яңа эшли башлаган Рүзәлгә тиешле игътибар, ярдәм күрсәтелә. Ул гыйбрәтле язмышлы күренекле шәхесләр белән очраша, уңышлы, кызыклы тапшырулар әзерли, кайберләрен эфирда үзе алып бара. Телевидениедә эшләү Рүзәлне рухи яктан баета, белемен, язу, сөйләү осталыгын арттырырга ярдәм итә.

Шулай берничә ел эшләгәч, аны университеттан элекке диплом җитәкчесе профессор М.З.Зәкиев, Казан педагогика институты ректоры итеп билгеләнгәч, үзенә аспирантурага чакырып ала. Рүзәл аспирантурада, тәрҗемә теориясе буенча кандидатлык диссертациясен уңышлы язып, тиешле вакытыннан алда яклап, филология фәннәре кандидаты дәрәҗәсенә лаек була.

Рүзәл Юсуповның Казан педагогика институтында (университетында) эшләгән еллары – гомерендәге күп игелекле гамәлләр кылган чоры. Ул монда, моңарчы алган белемен, яшәү тәҗрибәсен кулланып, егәрлеген-куәтен аямыйча хезмәт итә. Югары уку йорты укытучысының барлык баскычларын – ассистент, өлкән укытучы, доцент, профессор этапларын узып, студентлар группасы җитәкчесе, декан урынбасары, декан, тарих-филология факультеты партоешмасы секретаре вазыйфаларын башкарып, Казан дәүләт педагогика институтының ректоры дәрәҗәсенә җитә.

Россиядә, Санкт-Петербург һәм Мәскәү югары педагогика уку йортларыннан кала, өченче булып ачылган зур тарихлы Казан педагогика институтының ректоры итеп билгеләнү, Кышкар авылының җиделлык мәктәбен тәмамлап, мөстәкыйль рәвештә олы дөнья юлына чыккан кешенең олы хезмәтләрен, казанышларын тану була. Ул бу зур вазыйфага, Мәскәүдә СССР Фәннәр академиясенең Рус теле институтында «Татар һәм рус телләренең лексик-фразеологик системасындагы гомуми һәм үзенчәлекле сыйфатлар» дигән җитди темага докторлык диссертациясен яклап, монографияләр, фәнни мәкаләләр язып, профессор исеменә ирешкәннән соң билгеләнә.

1986–2002 еллар – Р.А.Юсуповның ректорлык чоры – Казан педагогика институты (университеты) өчен чын мәгънәсендә реформа еллары була. Вуз нык үзгәрә, сан ягыннан да, сыйфат ягыннан да күзгә күренеп үсә. Үзгәреш аның бөтен өлкәләрендә дә бара, рейтингы буенча Россия педагогика уку йортларының беренче унлыгына кереп, илнең әйдәп баручы вузларының берсенә әверелә.

Бу чорда факультетлар һәм кафедраларның саны икеләтә күбәя, студентлар һәм укытучылар контингенты да арта, яңа белгечлекләр кертелә. Казан дәүләт педагогика университетының Яр Чаллы филиалы оештырыла, Казан педуниверситетының чит ил вузлары белән элемтәләре урнаштырыла, докторлык диссертацияләре яклау советлары ачыла, укыту өчен материаль база ныгый. Бу елларда вузның фәнни потенциалы да көчәя: 1986 елда фән докторлары һәм профессорлар саны 16 булса, 2002 елда алар 60 ка җитә, мактаулы исемнәргә лаеклы укытучыларның, фәннәр академияләре әгъзалары, Сорос профессорлары һәм доцентларының саны күбәя.

Казан педагогика институты коллективының киеренке һәм тырыш хезмәте нәтиҗәсендә 1994 елда яңа статус ала – педагогика университетына әверелә.

Республиканы зур белемле, тәрбия эшенә тагын да әзерлеклерәк укытучылар белән тәэмин итү бурычы педагогика уку йортларыннан яңа белгечлекләр һәм дисциплиналар кертүне, уку планнарын, программаларын камилләштерүне һәм үзгәртүне, булачак белгечләрнең сыйфатын күтәрүне таләп итә. Рүзәл Юсуповка бу мөһим бурычларны гамәлгә ашыру эшенә җиң сызганып керешергә, коллективны шушы бурычны үтәүгә тупларга, һәр эшкә төшенеп, кирәк чакта һәркемгә ярдәм итәргә, кешеләргә дә, үзенә дә таләпләрне арттыра барырга туры килә. Бу чорда барлык белгечлекләрнең дә уку планнарына ректор инициативасы белән яшь буынны тормышка, һөнәргә өйрәтү һәм тәрбияләү өчен аеруча кирәкле дисциплиналар, мәсәлән, музыка тәрбиясе нигезләре, сөйләм культурасы, сөйләм техникасы, риторика, хореография кертелә һәм тиешле кафедралар ачыла.

Р.А.Юсупов ректорлыгына кадәр Казан педагогика институтында традицион рәвештә өч көнбатыш – инглиз, немец, француз телләре укытылып килгән. Илебезнең көнчыгыш дәүләтләре белән бәйләнеше киңәя баруын исәпкә алып, Казан педуниверситеты, инглиз теле белән бергә, көнчыгыш халыклары телләрен – гарәп, төрек, фарсы, һинд, кытай, япон телләрен дә белә торган белгечләр әзерли башлый.

Р.Юсупов халык депутатларының Казан шәһәре Советына сайлана һәм анда мәгариф комиссиясе председателе була.

Рүзәл Юсупов тормышындагы аеручы истәлекле һәм бай эчтәлекле сәхифәләр аның 1990-1995 елларда республикабызның чын демократик юл белән төзелгән һәм эшләгән бердәнбер парламенты Татарстанның Югары Советында эшләгән чоры белән бәйле. Р.А.Юсупов анда депутатлыкка альтернатив нигездә җиде кандидат арасыннан сайлап куела. Ул парламентта иң актив депутатларның берсе була. Университеттагы төп эшеннән аерылмыйча, җәмәгать эше тәртибендә милләт һәм мәдәният мәсьәләләре буенча даими комиссия (хәзергечә, комитет) председателе вазыйфаларын башкара, аеруча мөһим закон проектларын төзүдә һәм кабул итүдә актив катнаша. Аны күп кешеләр парламент сессияләрендә республикабыз тормышының иң әһәмиятле мәсьәләләре буенча еш кына тәэсирле чыгышлар ясаган депутат буларак хәзер дә хәтерли.

Рүзәл Юсуповның тагын бер күркәм эше бар. Республикабызда демократияне җәелдерү, дәүләтебез төзелешен ныгыту, мәдәниятебезне, рухи тормышыбызны җанландыру һәм алга җибәрү, шулай ук Татарстан халкының яшәү шартларын яхшыртуга ярдәм итү максатында, 1992 ел ахырында Татарстанның Республика партиясе оештырыла. Бу изге эшне башлап йөрүчеләр халкыбызның патриотлары Марат Мөлеков, Гаял Мортазин, Фираз Харисов, Рәшит Вәгыйзов, Фарсель Зыятдинов, Әмир Мәхмүдов, Рәгъде Халитов, Николай Мышев, Әгъзам Фәйзрахманов һәм тагын кайбер кешеләр була. Оештыру җыелышында партиянең рәисе итеп Рүзәл Юсуповны сайлап куялар. Бу аның моңарчы булган игелекле хезмәтләрен тану һәм зур ышаныч күрсәтү була. Ышанычны аклап, партияне гамәлгә кертү өчен, Рүзәлгә шактый зур көч сарыф итәргә туры килә. Ул профессор Фираз Харисов белән партиянең программасын һәм уставын төзү, аны Юстиция министлыгында теркәтү, татар һәм рус телләрендә «Татарстан Республикасы» исемле партия газетасын оештыру эшләрен башкара. Бу газета көн үзгәгендә торган мәсьәләләргә караган җитди мәгълүмат игълан итү белән нәтиҗәле шөгыльләнеп килә.

«Милләтебез иминлеге сагында» китабы аша олпат галим, күренекле җәмәгать эшлеклесе, публицист Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсупов кылган гамәлләрнең бик кечкенә генә өлешен дә күрсәтеп бетерү мөмкин түгел (кызыксынган кешеләр китапның үзен укыр). Татар халкының турылыклы улы Рүзәл Юсупов, олы яшьтә булуына карамастан, хәзер дә милләтебезнең якты киләчәге өчен җан атып йөрүчеләрнең алгы сафында бара.

Фираз ХАРИСОВ,
педагогика фәннәре докторы,
профессор, 1991-1998 елларда
Казан педагогика университетының
беренче проректоры.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

19 ноябрь (шимбә). ***Рабигүл ахир аеның 25 нче көне. 25 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 0.55 сәгатьтә калка, 14.14 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 8.04 сәгать.***

Акыл җыю көне. Интуициягә таянырга була. Күргән төшләр рас килә. Сизү әгъзалары, баш, колак, кан тамырлары зәгыйфь. Энергияне юк-барга сарыф итәргә ярамый. Ач тору файдалы.

Ютәл интектерсә

Тигез микъдарда алынган бака яфрагы һәм кура җиләге яфракларын, наратбаш үләнен ярты литр суда кайнаталар, 2сәгать төнәтәләр, көн буена әз-әзләп эчәләр. Яисә лимонны 10 минут бue суда пешереп, урталай кисеп, согын марля аша сыгалар, шуңа 2 аш кашыгы глицерин, 3 аш кашыгы бал кушып яхшылап болгаталар да, көненә 3 тапкыр, ашар алдыннан, 1 әр чәй кашыгы кабалар, йоклар алдыннан да 1 чәй кашыгы эчәләр.

20 ноябрь (якшәмбе). ***Рабигүл ахир аеның 26 нчы көне. 26 нчы Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 2.16 сәгатьтә калка, 14.21 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 8.00 сәгать.***

Һәртөрле вәсвәсәләргә бай көн. Әйләнә-тирә дөньяны кабул итү кискенләшә, тәэсирләнүчәнлек арта, чит кеше йогынтысына бирешүчәнлек көчәя. Килешүләр төзү уңышлы. Нерв системасы, аяк зәгыйфь. Теш дәвалату өчен начар вакыт. Балык, мүк җиләге, сөт ризыклары ашау файдалы.

Арпа чыкса

Матдәләр алмашы бозылганда, авитаминоз, азканлылык, хәлсезлек булганда, күзгә арпа чыгып җәфалый. Марля капчыкка салып кайнатып, бераз суытылган җитен орлыгы куеп торалар. Күзне куе чәй белән юалар. Арпа чыга башлаган күз кабагын чистартылган сарымсак телеме белән сыпыралар. 15 г тырнак гөл чәчәген 200мл кайнар суда җылы урында 30 минут төнәтәләр дә, мамык кисәген чылатып, күзгә куялар. Яисә шырпы башы кадәр мумие кисәген 50 мл дистилляцияләнгән суда эретеп, мамыкны шуңа манып, арпага ябалар. Яки кипкән гөлбадран чәчәгенең 4-5 төймәсен көненә 5 тапкыр ашыйлар, артыннан кайнаган чиста су эчәләр.

21 ноябрь (дүшәмбе). ***Рабигүл ахир аеның 27 нче көне. 27 нче Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында, 3.40 сәгатьтә калка, 14.29 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 7.57 сәгать.***

Бу көннәрдә организм хәлсез, шунлыктан күбрәк йоклау файдалы. Нерв системасы, сизү әгъзалары зәгыйфь. Кан һәм лимфа авырулары кискенләшергә мөмкин. Кан басымын контрольдә тоту сорала.

Көнбагыш сихәте

Кан басымы югары булганда, болай дәваланалар. Ярты литрлы банкадагы көнбагышны юып, 2 литр салкын суга салалар, кайнатып чыгарып, сүрән утта 2 сәгать пешерәләр. Суыткач, сөзеп, көн буена әз-әзләп эчеп бетерәләр.

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга карап кырын

22 ноябрь (сишәмбе). ***Рабигуль ахир аеның 28 нче көне. 28 нче Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында, 5.08 сәгатьтә калка, 14.38 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 7.54 сәгать.***

Айның иң яхшы көннәреннән берсе. Энергетикасы бик уңай. Көтелмәгән очрашулар берсеннән-берсе кызыклырак булачак. Хисләр тернәкләнә, аралашу теләге уяна. Сизү әгъзалары, аеруча күзләр зәгыйфь. Кан басымын контрольдә тоту зарур. Организмны чистарту, ач тору уңай нәтиҗә бирә.

Тоз тирене чистарта

Баш тиресендәге коры экземадан котылу өчен, атнасына 1 тапкыр, башны җылы су белән югач, 15 минут буе тиресенә аш тозы ышкыйлар. Аннан соң су белән чайкыйлар. Баш тиресе экземадан тулысынча савыксын өчен, шундый 6 процедура җитә.

23 ноябрь (чәршәмбе). ***Рабигуль ахир аеның 29 нчы көне. 29 нчы Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 6.42 сәгатьтә калка, 14.52 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 7.50 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Бернинди вәгъдәләргә дә ышанырга ярамый. Бизләр системасы, кан тамырлары, эчәклек зәгыйфь. Үзәңне үпкәләткән кешеләрне кичерү зарур.

Артриттан дәва

Артритны кисәтү өчен болай дәваланып карарга була. 15 дәфнә яфрагын 1 литр суда кайнатып чыгарып, сүрән утта 5минут пешерәләр, аннары термоска бушатып, 3-4 сәгать төнәтәләр. Сөзеп, суыталар, 10 сәгать эчендә әкренләп әз-әзләп эчеп бетерәләр. Мондый процедураны елына 1 тапкыр өч көн рәттән башкару яхшы.

24 ноябрь (пәнҗешәмбе). ***Рабигуль ахир аеның 30 нчы көне. 1 нче, 2 нче Ай тәүлекләре. Ай Укчы йолдызлыгында, 8.21 сәгатьтә калка, 15.13 сәгатьтә бата. 01 сәгать 57 минуттан яңа Ай. Көн озынлыгы 7.47 сәгать.***

Гармониягә ирешү көне. Иҗат белән шөгыльләнү, айлык план төзү яхшы. Интуиция арта. Баш һәм йөрәк зәгыйфь. Яңа туган Ай Җир белән Кояш арасында, үзенең караңгы ягы белән Җиргә караган. Ай идарә итә торган һәрнәрсә – хисләр, кәеф, хәтер, кан басымы зәгыйфь. Кан басымы болай да түбән булган гипотониклар өчен бигрәк тә авыр вакыт. Бу чорда укуда уңышлар, тиз савыгу, югары эшчәнлеккә өметләнергә ярамый. Ашаганда талымлы булу хәерле. Аралашуны чикләү зарур.

25 ноябрь (җомга). ***Җөмәдел әүвәл аеның 1 нче көне. 3 нче Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 9.55 сәгатьтә калка, 15.58 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 7.45 сәгать.***

Бик актив көн, хәвеф-хәтәр инстинкты, агрессия белән бәйле. Бүген чирләп китү ихтыяр көченең җитәрлек булмавын күрсәтә. Күзне арытмаска кирәк.

Эремчекле кабартма

1 стакан кефир, 100 г эремчек, 2-3 йомырка, ярты стакан шикәр, тәменчә тоз, бер чеметем содага он өстәп, коймакныкыннан куерак камыр туглыйлар. Аш кашыгы белән салып, майда кыздыралар. Кәгазь сөлгегә маен сеңдергәч, тәлинкәгә матурлап өеп, өстенә шикәр оны сибәләр. Кашыкка камыр ябышмасын өчен, аны гел стакандагы суга манып алалар.

Милли бизәкләр модага керә

Соңгы елларда яшьләр арасында да дини, милли мәдәниятне, борынгы бизәкләрне саклауга омтылучылар арта. Шул исәптән гарәп каллиграфиясе белән кызыксынучылар да байтак. Гүзәл Хәйбуллова да шундый талантлы милләттәшләребезнең берсе.

Самаранның «Яктылык» татар мәктәбен тәмамлаганнан соң, Гүзәл архитектура-төзелеш академиясенә укырга керә. Хәзерге вакытта ул бишенче курс студенты, диплом проекты яза.

– Мин үземне белгәннән бирле рәсем ясарга ярата идем. Хәтта уенчыклар белән уйнау да мине кызыксындырмый иде. Икенче сыйныфта укыганда, мине әнием, мавыгуымны хуплап, сәнгать мәктәбенә укырга бирде. Анда төрле техникада рәсем, юеш балчыктан скульптуралар ясарга өйрәндем. Аннан соң Г.Зингер исемендәге беренче сәнгать мәктәбендә укыдым. Тулаем алганда, югары уку йортына кергәнче, мин рәсем сәнгате юнәлешендә тугыз ел белем алдым. Гаиләбездә рәсем ясау белән бик кызыксынмыйлар. Шуңа да карамастан, әти-әнием, рәсемнәремне югары бәяләп, тагын да тырышыбрак эшләргә этәргеч биреп торды һәм бүген дә минем иң беренче тәнкыйтьчеләрем булып кала, – дип елмая танышым.

Ислам дине мәдәнияте, гарәп графикасы мәкаләбез героена балачактан таныш икән. Алты яшеннән Гүзәл Самараның җәмигъ мәчете каршында эшләп килгән «Нур» мәдрәсәсендә укый. Анда гарәпчә укырга һәм язарга өйрәнә, төрле ярышларда, олимпиадаларда катнашып, җиңүләр яулый.

– Бизәкле гарәп язмасы мине шундук гашыйк итте. Хәтта дәрестә утырганда да дәфтәремдә гарәп хәрефләрен төрлечә ясап карадым, килеп чыкканына соклана идем, – дип искә ала Гүзәл. – Архитектура академиясендә укый башлагач, рәсем сәнгате белән ныклап шөгыльләнү теләге тагын да көчәйде. Ә гарәп каллиграфиясенә карата мәхәббәтем рәссам буларак үз стилемне билгеләргә ярдәм итте. Халкым тарихы, мәдәнияте минем эшләремне башкалардан аермалырак, үзенчәлеклерәк итәргә булыша. Картиналарымда милли орнаментларны гарәп каллиграфиясе белән үрелдереп, татар халкының ислам дине белән тыгыз бәйләнештә булуын чагылдырам.

Татар халык бизәкләре белән дә мәктәптә укыганда ук кызыксына башладым. Казанга баргач, шушы темага кагылышлы китаплар, журналлар сатып алып, аларның килеп чыгышын, мәгънәләрен тирәнтен өйрәндем. Кызганыч, чигүле сөлгеләр, алъяпкычлар, яулыклар, мендәр тышлары бүген күбрәк музейларда һәм төрле күргәзмәләрдә генә очрый. Бу гүзәллекне заман көнкүрешенә яраклаштырып, актуальләштереп, кулланышка кайтарасым килә. Шуңа күрә заманча сәнгать ярдәмендә милли бизәкләребезне Татарстаннан читтә дә танытырга телим, аларны кием һәм төзелеш элементы буларак кулланышка кертәсем килә.

«Яктылык»та «Мин татарча сөйләшәм» хәрәкәте вәкилләре белән очрашу барышында бер спикерның: «Туган тел халык белән бергә үсәргә һәм алга атларга тиеш. Ул борынгы әкиятләр һәм музей экспонатлары булып калырга тиеш түгел, көнкүрештә дә булырга тиеш», – дигән сүзләре мәңгелеккә күңелемә сеңеп калды. Мин бу сүзләр белән килешәм һәм иҗатым аша аларны башкаларга да җиткерергә тырышам.

Гүзәлнең бу юнәлештә ясаган беренче адымнарын бик уңышлы, дип саныйм. Чөнки күптән түгел генә дәүләт телерадиокомпаниясе аны тапшыруга чакырган иде. Милләттәшебезнең картиналары алып баручыларда зур кызыксыну уятты. Алар, татар кешеләре булмаса да, Гүзәлнең эшләрен сатып алырга теләк белдерде.

– Офис диварларын бизәүдә ярдәм итүемне, киемнәрен башкалардан аермалы итеп ясавымны сораучылар бар. Ә менә машиналар бизәп караганым юк әлегә. Бик кыйммәтле нәрсә бит, бераз шикләнәм. Гомумән, бизәкләрне электрон форматта ясап, төрле әсләкләргә төшерергә була. Хәзерге вакытта мин картиналарыма неон җепләр кушып карыйм. Шул рәвешле аларны караңгыда да күреп булачак. Үз чиратында алар яктырткыч ролен дә башкара алачак.

Хыялымда тагын бер картина туды әле. Анда чәчәкләргә күмелгән милли кием кигән татар кызы сурәтләнәчәк, картина абстракция стилендә башкарылачак. Татар орнаментларында лалә чәчәге бик популяр. Картиналарымда бу чәчәккә җан өреп, талгын гына искән җилдә аның сизелер-сизелмәс кенә тибрәнгәнне тоелырлык итеп ясарга тырышам.

Киләчәктә рәсем сәнгате белән мавыгуымны төп һөнәрем белән үрелдереп алып барырга ниятлим. Архитектор буларак, проектларымны милли орнаментлар һәм гарәп каллиграфиясе элементларын кертеп башкарырга уйлыйм. Шулай ук банкет яки башка масштаблы чаралар уздыру өчен махсус зур залларны үз стилемдә бизәргә хыялланам, – ди Гүзәл.

Эльмира СӘЙФУЛЛИНА.
«Бердәмлек».

Тамаша заллары чакыра

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

18 ноябрь – «Әтәч менгән читәнгә» (А.Гыйләҗев).
19 ноябрь – 12.00 – «Хуш, авылым» (А.Җаббаров). 17.00 – Шәрык клубында Яңа шимбәчеләр клубында актриса Ләйсән Фәйзуллина белән очрашу. 18.00 Зур залда – «Сөясеңме, сөймисеңме...» (Ф.Бүләков). Кече залда – «Хуш, авылым. Хыял» (А.Җаббаров).
20 ноябрь – Шәрык клубында – «Бичара кыз» (Г.Ильяси). Зур залда – «Өйләнәм.tat» (И.Зәйниев).
22 ноябрь – 14.00 – «Гөргөри кияүләре» (Т.Миңнуллин). 19.00 – «Җәйнең бер көнендә» (Й.Фоссе).
23 ноябрь – «Сүнгән йолдызлар» (К.Тинчурин).
24 ноябрь – Зур залда – «Җанкисәккәем» (Т.Миңнуллин). Кече залда – «Көл» (К.Митани).
25 ноябрь – «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

18,19 ноябрь – «Алтын Урда» (Р.Әхиярова).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

18 ноябрь – «Алай түгел, болай ул» (Т.Миңнуллин).
19 ноябрь – 12.00 – «Асылкош» (Р.Мөхәммәтшин). 17.00 – «Кияү урлау» (С.Юзеев әсәре, Х.Ибраһим тәрҗемәсе).
20 ноябрь – «Гашыйклар тавы» (И.Юзеев).
22 ноябрь – «Өч аршын җир» (А.Гыйләҗев).
23 ноябрь – «Утка очкан күбәләктәй...» (Н.Гыйматдинова әсәре, Т.Хәләф инсценировкасы).
24 ноябрь – «Хан кызы Турандык» (К.Гоцци, К.Тинчурин).
25 ноябрь – «Син бит минем бергенәм» (И.Мәхмүтова).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

18 ноябрь – «Супер кияү» (Т.Миңнуллин).
19 ноябрь – «Йосыф» (Кол Гали).
20 ноябрь – «Арыну» (Т.Кулов, А.Әхмәдиев).
22 ноябрь – 13.00 – «Асылкош җыры» (Р.Мөхәммәтшин). 18.00 – «Йөз Тукай» тамашасы.

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

18 ноябрь – «Дитя Аллаха» (Н.Гумилев).
19 ноябрь – Фойеда – «Не хочу, не буду» (П.Геннадьева), зур залда – «Золушка» (Е.Шварц).
20 ноябрь – Зур залда – «Красная шапочка» (Ш.Перро). Кече залда – «Җырла, Курай!.. Уйна, Шомбай!» (С.Дорожко).
24 ноябрь – «Авыл эте Акбай» (Т.Миңнуллин).
25 ноябрь – «Әлфия» (И.Зәйниев).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

19 ноябрь – Татарстан Республикасы филармониясе джаз оркестры һәм София Ацбеха-Негга концерты.
20 ноябрь – 11.00 – Балалар өчен джаз концерты. 18.00 – Татарстан Республикасы фольклор музыкасы дәүләт ансамбле концерты.
23 ноябрь – Роберт Юлдашев һәм «Курайчы» ансамбле концерты.
24 ноябрь – Алла Рид һәм «Симха» ансамбле концерты.

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

19 ноябрь – С.Гобәйдуллина исемендәге «Concordia» халыкара заманча музыка фестивале кысаларында Татарстан Республикасы дәүләт симфоник оркестры концерты. Дирижер – Дж. Пехливанян, солист – А.Рамм (виолончель).
20 ноябрь – Татарстан Республикасы кыллы квартетының «Играет скрипка, сердце разрывая...» дип исемләнгән концерты.
23 ноябрь – С.Гобәйдуллина исемендәге «Concordia» халыкара заманча музыка фестивале кысаларында Татарстан Республикасы дәүләт симфоник оркестры концерты. Дирижер – А.Мустонен.

Марсель БАКИРОВ кытыклары

Артистлар һәм язучылар тормышыннан



Әлфия Афзалова бер авылда концерт куйганда, сәхнәгә бер хатын менгән, ди. Тамаша барышын бүлдереп, бу бөтен халык алдында Әлфиягә сүз каткан:

– Бәлки минем турыда ишеткәнегез дә бардыр. Мине авылда тел остасы, бәет, шигырь чыгаручы, дип йөртәләр. Менә сез килүгә атап та бер шигырь чыгардым әле, – дип, кулындагы дәфтәрен күрсәткән.

– Бик әйбәт, бик хуш, апа җаным. Йә, шигыреңне безгә дә укып күрсәт, алайса, – дигән Әлфия.

Шигырь чыгаручы хатын, тавышына тантаналылык бирергә тырышып, укып җибәргән:

Сез килмәдегез базардан,
Сез килдегез Казаннан;
Сез килмәдегез сарык суярга,
Сез килдегез концерт куярга.

* * *

Мәскәүдә әдәбият институтында укыган вакытында Габделхәй Сабитов «картаебрак» барган бер кыз янына йөрергә ияләшкән. Чираттагы баруында ул, кызның ахирәте белән таныштырам дип, бүлмәдәшен дә ияртә. Килсәләр, кызның авызы колагына кадәр ерылган, ди. Нигә шатлануын боларга да белдергән:

– Киләсе җомгада мин кияүгә чыгам, – дигән ул тантаналы тавыш белән.

– Кемгә чыгасың?

– Чиләгенә күрә капкачы табыла инде ул.

Габделхәй хәйләле елмаеп әйткән:

– Чиләгенең нинди икәнен без беләбез инде. Капкачы кем, шуны әйт син.

* * *

Университетка укырга кергәндә, булачак шагыйрә Салисә Гәрәевага тарихтан имтихан бирергә туры килгән. Имтиханны бер ассистент белән доцент Аркадий Семенович Шофман (соңыннан ул профессор булды) ала икән. Бу каршыларына килеп баскан Салисәгә, билгеләр куела торган кәгазен алырга дип, кулын сузган. Сузылган кулны (җитмәсә, доцент кулы бит!) ничек кысмыйсың инде?! Салисәбез җебеп калмаган, имтихан алучының кулын учлап тоткан да аска-өскә селкетә-селкетә исәнләшкән.

* * *

Шагыйрь Илдар Юзеев белән композитор Фасил Әхмәтов Мөслимдә сәнгать үнкөнлеге вакытында язучылар һәм артистлар төркеме белән авылдан авылга очрашуларда катнашып йөргән. Клубтан соң Казан кунаклары көн дә мул сый мәҗлесендә кинәнгәннәр. Мөслимгә кайтып төшкәч, Илдар белән Фасил Әхмәтовны бер якын танышлары ашка алган һәм, әлбәттә инде, иң тәмле ризык дип, тавык та кыздырып куйган. Илдарның капкадан керүе булган, ишек алдында чүпләнеп йөргән тавыкларга күзе төшеп укшый ук башлаган. Һәм, аклангандай, әйткән:

— Көн дә тавык ашый-ашый җилән беттем, маемладым. Тере тавык күрсәм дә, косасым килә...

Ишеткәннәрдән

– Җәннәттә бер ир кешенең җитмеш хур кызы булачак, ди, икән бит.

– Әйтәм җирле ирләр, хатыннарын калдырып, иртә үләргә ашыгалар.

***

Әби кеше:

– Балакаемның сөннәте әрәм китте – марҗага өйләнде.

* * *

– Яңа күлмәгем белән генә котлама, кияүгә чыгуым белән дә котла.

– Шулаймыни?! Котлыйм, ахирәтем. Җылы өстеңдә тузсын.

* * *

– Кеше бар, дип торам, син икәнсең.

* * *

Яшүсмер илле яше дә тулмаган ир-агага:

– Абзый, син бик яшь күренәсең, нык саклангансың.

– Ничә яшь бирер идең?

– Бер сиксән яшь бармы әле?

* * *

– Яшь чакта, кызлар күрдемме, дәртем-дәрманым кузгала иде. Хәзер, күзем начар күрә башлагач, әллә нәрсә булды. Күзне сакларга кирәк булган икән.

* * *

– Синең янга эшкә урнашырга кодалыйлар. Әмин риза түгел: бер казанга ике тәкә башы сыймый.

– Һай, дустым, син бәрән башы гына бит әле.

* * *

– Нинди бәхетле гаилә! Аларның бергә яшәүләренә быел алтмыш ел тула икән.

– Ничек чыдаганнар, диген син! Бер-берсеннән тәмам туеп беткәннәрдер.

* * *

Әби кеше:

– Балаларны аңламассың хәзер. Юньләп татарча да, бер дога да белмәгән кызларына Алла исеме кушканнар.

Файдалы киңәшләр

Ир кеше ул кулга тиз ияләшә торган умырткалы хайван. Җаена торсаң, аны ат итеп җигәргә дә, сыер итеп саварга да мөмкин.

* * *

Хатын кеше, авызында бер генә теше калса да, ирен чәйнәп өзә ала. Аның тешләреннән сакланыйм, дисәң, энҗе тешле яшь кызларга кызыгуыңны сиздермә.

* * *

– Урамда очраган бабайлар белән исәнләшеп йөр – атаң булуы бар, якын-тирәңдәге бала-чаганың башын сыйпап кит – балаң булуы бар.

* * *

Уку елы алдыннан үткәрелә торган конференциядән чыккач, кайбер мишәр укытучылар:

– Инде үләргә кятабыз, – дип куаналар икән. Казаннан килгән вәкилнең сүзләре боларны исләренә килергә мәҗбүр иткән:

– Укытучы башыгыз белән алай дип тормагыз инде, коллегалар. Үләргә түгел, өйләрегезгә кайтырга җыенасыз бит.

Куратор сәгатендә, яки Хәйләсез дөнья файдасыз

– Студент иптәшләр, барыгызның да исендәдер, без узган җыелышта группада өлгерешнең начар булуы, күп дәрес калдыруыгыз турында сөйләшкән идек.

– Үткән эшкә салават, абый. Булган эш булган, үкенүдән узган.

– Ләкин мин бүген шул ук темага яңадан әйләнеп кайтырга тиешмен. Һаман төзәлергә уйламыйсыз. Күпме артта сөйрәлергә мөмкин инде?

– Чыбыктан төз булып булмый, абый. Дүрт аяклы ат та абына.

– Әнә икенче группаны мактап бетерерлек түгел. Барысы да укырга атлыгып торалар.

– Күрше тавыгы каз кебек, йомыркасы баш кебек була инде.

– Укытучыгыз зарлана: узган семинарга да әзерлексез килгәнсез. Сүз берләшкәндәй, барыгыз да авызыгызга су капкан кебек утыргансыз.

– Бәй, остаз барда телең тый, диләр ич. Сөйләвең көмеш булса да, тик торуың – алтын.

– Тик тормыйсыз шул, лекция вакытында гел шаулашып утырасыз. Укытучы тактага берәр нәрсә язарга тотынса, шундук базар ясыйсыз.

– Берәүнең кулы уйный, берәүнең – теле. Үзегез беләсез: күп авыздан күп сүз чыгар.

– Алай бик күп сөйләргә яратасыз икән, нигә соң сез тел фәннәрен ныклап үзләштермисез, нигә тел культурасына өйрәнмисез?

– Сөйдергән дә тел, биздергән дә тел, абый.

– Акланырга дисәң, сез оста инде. Әменә китапханәгә уку залына нигә йөрмисез? Яшь укытучылар, аспирантлар шунда, әсез берәм-берәм генә.

– Тауга карап, тау булып булмый ич инде. Сыерлар су эчкәндә, бозаулар боз ялыйлар.

– Болай булсагыз, имтиханда да бозау хәлендә калырбыз дип борчылмыйсызмыни? Анда бит сезнең кәҗә маегызны чыгарачаклар.

